ХӘБӘРЛӘР



**Казанда Татарстан Президенты катнашында Галиев мәчете ачылды**

2 бит

ХӘБӘРЛӘР



**Хәләл продукция нинди булырга тиеш?**

3 бит

ИСЛАМ МӘГАРИФЕ



**Исламның асылын гыйлем аша гына җиткереп була**

10 бит


# ДИН вә Мәгыйшәт

6+

*Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез! (Коръән, 3:103)*

*Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!*

№ 12 (245). ДЕКАБРЬ – 2015 / САФӘР-РАБИГЫЛЬӘҮВӘЛ / 1437

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



реклама

AZAN
ИСЛАМ АВАЗЫ
ИНТЕРНЕТ-РАДИОСЫ
www.radioazan.ru


# Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның Мәүлид бәйрәме белән котлавы



Әссәләәмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү!

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән барлык мөселманнарны Мәүлид бәйрәме белән ихластан котлыйм!

Мәүлид – ислам динен кыйммәтләгән, зурлаган кичәләрнең берсе. Чөнки бу кичәдә бөтен кешелек дөньясына соңгы пәйгамбәр буларак җибәрелгән Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дөньяга килгән. Пәйгамбәребезнең туган вакыты миладите исәпнең 571 нче елына туры килә, рабигыльәүвәл аеның 11-12 нче көннәре арасындагы кичә дип исәпләнелә.

Сөекле Пәйгамбәребез кешеләрнең иң юмарты, иң күркәм холыклысы, иң сабыры һәм иң мәгърифәтлесе булган һәм ул бар кешелек дөньясына Коръән нурын, ислам әхлагын җиткергән. Аллаһы Тәгалә Изге китапны Пәйгамбәребезгә индереп, аны олылаган һәм боерган: "Ий Мөхәммәд! Кешеләргә Аллаһның юмартлыгы вә рәхмәте илә индерелгән Коръән белән сөйлә һәм аларны Коръән белән гамәл кылырга өндә!" ("Юныс"сүрәсе, 58 аять).

Пәйгамбәребез саллаллаһу гәләйһи вә сәлләмнең игелекле үгет-нәсыйхәтләре, хәдисләре Раббыбыз кушканча яшәргә, мәрхәмәтле булырга өйрәтә, туры юлдан барырга ярдәм итә. Аллаһы Тәгаләнең Мөхәммәд Пәйгамбәрне Рәсүл итеп җибәрүе – безгә күрсәткән бик зур рәхим-шәфкате.

Аллаһ Рәсүле бар галәмгә рәхмәт буларак җибәрелгән. Коръәндә "Әнбия" сүрәсенең 107 нче аятендә бу хакта: "(Ий Мөхәммәд!) без сине бары тик рәхмәт билгесе итеп галәмдәге халыкларга күндердек", – дип әйтелә.

Мәүлид – Аллаһ Рәсүле дөньяга килүгә ихлас күңелдән шатлануны белдерә торган вакыт. Бу кичәдә сәдакалар бирү, догалар кылу, салаватлар әйтү саваплы гамәлләрдән санала. "Мәүлидне олылаган һәр кеше ислам диненең җанлануына ярдәм итә", – дип әйткән дин белгечләре.

Барчабызга да Аллаһы Сүбхәәнәһү вә Тәгаләнең рәхим-шәфкате язсын! Өммәтебезгә Пәйгамбәребез саллаллаһу гәләйһи вә сәлләмнең сөннәтенә иярген хәлдә яшәргә насыйп итсә иде! Амин.

## РИИда Бөтенроссия олимпиадасы җиңүчеләрен бүләкләделәр

Тантаналы чарада Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, мөфти урынбасары, РИИ ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин, Казан шәһәре мөхтәсибе Мансур хәзрәт Җәләлетдинов, Казан (Идел буе) федераль университетының халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм Көнчыгышны өйрәнү институты директоры Рамил Хәйретдинов, Казан шәһәре мэриясенең телләрне үстерү һәм иҗтимагый оешмалар белән элемтә булеге баш белгече Илгиз Сарманов катнашты.

Быел сигезенче тапкыр оештырылган олимпиадада Россиянең төрле төбәкләрендәге мөселман уку йортлары студентлары катнашты. Алар "Ислам хокукы", "Дин нигезләре" һәм "Гарәп теле" номинацияләрендә көч сынашты. Бу өлкәдә белемнәрен сынап карарга теләүчеләр тест формасында язма эш эшләде. "Гарәп теле" номинациясендә – гарәпчә сөйләү, ә ислам фәннәре буенча катнашучылар матур һәм дөрес итеп Коръән укып күрсәтергә тиеш иде.

Җиңүчеләргә, призерларга дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр тапшырылды.

"Дин нигезләре" номинациясе:

Арби Сөләйманов – Кунт-Хаҗи исемендәге Россия ислам университеты,

Мөхәммәд Мансуров – Дагыстан ислам университеты,

Сорбонхуча Гияев – Мәрьям Солтанова исемендәге ислам көллияте

«Гарәп теле» номинациясе:

Наил Шаипов – Казан ислам университеты,

Мөхәммәд Исаев – Дагыстан ислам университеты,

Шәрабиддин Шәрабиддинов – Россия ислам институты,

Мөхәммәд Цолоев – Ингушетия ислам университеты

«Ислам хокукы» номинациясе:

Мурад Гасанов – Дагыстан ислам университеты,

Асламбек Мурадов – Кунт-Хаҗи исемендәге Россия ислам университеты,

Джабраил Джандигов – Ингушетия ислам университеты

Шуны да әйтергә кирәк, һәр номинациядә берәр шәкертк РИИ ректоры призы тапшырыла. Быел бу бүләккә Татарстан мөселман уку йортларында белем алучы шәкертләр ия булды:

Ибраһим Дәүләтов – Яр Чаллының "Ак мәчет" мәдрәсәсе,

Дилбәр Латыйпова – "Фәнис" мәдрәсәсе,

Илнур Ямалиев – Казан ислам университеты

# Казанда Татарстан Президенты катнашында Галиев мәчете ачылды

**Мәүлид бәйрәме алдыннан Россия Федерациясенең мәдәни мирас корылмасы һәм татар архитектурасы үрнәге булган Галиев мәчетен ачу тантанасы булды. Яңартылган мәчет ачылышында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, аның урынбасарлары, Казан һәм республика имамнары катнашты.**



Камил хәзрәт Президентны ел буе мәчеттә алып барылган эшләр белән якыннан таныштырды. "Бу мәчетнең тарихы зур, үзенчәлекле. Галиев мәчете ике гасыр дәвамында Казан мөселманнарының рухи үзәге булып торган. Барыгызны да шушы шатлыклы һәм сөенечле вакыйга белән котлыйм. Халкыбызга алга таба да Галиев мәчетенең яхшы йогынтысын, файдасын күрергә язсын", - диде Рөстәм Миңнеханов һәм якын арада Галиев йөртын төзекләндерү эшләре тәмамланачагын хәбәр итте.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, үз чыгышында, әлеге вакыйганың зур тарихи әһәмияткә ия булуын, Мәүлид бәйрәме алдыннан ачылуының аеруча куанычлы вакыйга булуын билгеләп үтте. "Аллаһы Тәгалә безгә бабаларыбыз салган һәм имамлык иткән мәчетне яңадан ачарга насыйп итте. Берара мәчет шактый тузган һәм ташландык хәлдә торды. 2014 елда дәүләт ярдәмендә реставрация эшләре башланды. Татарстан Президенты Рөстәм Нургали улы бу эштә зур ярдәм күрсәтте. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә әйтә: "Кем Аллаһының ризалыгын өмет итеп мәчет кора, Аллаһы ул бәндәсенең урынын җәннәттә итәр". Аллаһы Тәгалә мәчет төзүчеләргә үзенең әҗер-савапларын мулдан бирсен. Ике дөнья рәхәтен күрергә насыйп итсен! Мөхтәрәм җәмәгать, без Галиев мәчетенең халкыбызга иман һәм гыйлем нуры биреп торучы бер үзәк булуын телибез. Традицион рухи мирасыбызны, традицион ислам кыйммәтләрен саклап, яклап торучы шушындый тарихи мәчетләр кабат торгызылуга шатланабыз, шөкерләр кылабыз. Республикабызга Аллаһы Сүбхәәнәһү вә Тәгалә тынычлык, бәрәкәт бирсен, барыбызга да динебез кушканнарны үтәп яшәргә язсын!", – диде мөфти хәзрәтләре.

Кунакларның чыгышыннан соң Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев мәчеткә бәрәкәт, шәһәр халкына иман нуры биреп торучы үзәккә әверелүен сорап дога кылды, тәкъбир әйтелде. Кунакларга ТР МДН эшләгән "Галиев мәчете. Яңарыш тарихы" дип исемләнгән махсус китаплар таратылды. Соңыннан намаз укылды.

### БЕЛЕШМӘ

Галиев мәчете 1798-1801 елларда Казанның Иске татар бистәсе үзәгендә татар ислам архитектурасының XVIII гасыр классицизмы үрнәгендә төзелә. Ул сәүдәгәр Муса бин Мөслим бин Мамыш әс-Сәрдәви акчасына корылган. Аны шулай ук Муса бай мәчете, Бишенче мәхәллә мәчете, Тихвин урамындагы таш мәчет, Тихвин һәм Печән базары почмагындагы мәчет, Галиев мәчете дип тә йөрткәннәр. Мәчеттә беренче намаз 1800 елда укылган. Проектны башкаручы архитекторның исеме билгесез.

Шырдан авылында туган (хәзерге вакытта Татарстанның Яшел Үзән районына керә) Сәгыйть бин Әхмәт аның беренче имамнарыннан булган. Сәгыйтовлар нәселеннән Бишенче җамигъ мәчетнең соңгы мулласы итеп Мөхәммәтйосыф Габдесаттар углы Сәгыйтов санала. Аңа ярдәмче итеп мәхәллә халкы бай сәүдәгәр М. И. Галиевның улы – күренекле галим һәм педагогреформатор Галимҗан Баруди сайлый һәм нәтиҗәдә ул мәчет имамы була. Баруди үз янына яңача фикерләүче сәүдәгәрләрне һәм дин әһелләрен туплап, мәхәлләдә яңа ысуллар белән эшләүче зур «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен оештыруга ирешә. Ә Галиев мәчете мәхәлләсе Казан татарларының иҗтимагый-сәяси тормыш үзәгенә әверелә.

Әлеге мәчеттә Шиһабетдин Мәрҗани, Габдулла Тукай, Каюм Насыйри, Галимҗан Баруди, Галиәсгар Камал, Нәкый Исәнбәт һәм татар халкының мәдәнимәгърифәти үсешенә өлеш керткән башка бик күп олпат шәхесләре тәрбияләнгән, намаз укыган, дога кылган.

Совет чорында мәчет төрле сынауларны уза, 30 елларда манарасы сүтелә, 1992 елга кадәр биредә кунакханә, колхозчы йорты, төрле коммуналь хезмәтләр урнаша. 1992 елда бина мөселманнарга кайтарыла. 1998 елдан биредә Россия ислам университеты эшли. 2014 елга кадәр мәдрәсәнең хатынкызлар тулай торагы була.



# Мөселманнар Болгарда Мәүлид бәйрәмен билгеләп үтте

**Болгардагы Ак мәчеттә Мәүлид ән-Нәбигә багышланган бәйрәм чарасы узды. Анда ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте рәисе, мөфти Тәлгать хәзрәт Таҗетдин, РФ МДН рәисенең беренче урынбасары Дамир хәзрәт Мөхетдинов, хакимият органнары вәкилләре, Россия төбәкләре мөфтиләре, дин әһелләре, җәмәгать эшлеклеләре катнашты. Бәйрәмгә 200 дән артык кеше җыелган иде.**



shaimiev.tatar.ru



Өйлә намазыннан соң башланган бәйрәм чарасы. Коръән һәм догалар уку белән ачылды. Шуннан соң әлеге мәчетнең имам-хатыйбы Руслан хәзрәт Фәрхетдинов догалар укыды, "Нәшидел ислам", "РИУ шәкертләре" төркемнәре гарәп телендә нашидләр башкарды. Моннан тыш, Мәүлид ән-Нәби хакында сөйләнелде.

Минтимер Шәймиев әлеге чараның өченче тапкыр уздырылуын ассызыклады, һәм бары ихлас күңелдән башкарылган эшләрнең генә нәтиҗәле булуын билгеләп үтте. "Болгар җирендә, үзебезнең татар җирендә дин, рух булуы, аның торгызылуы – зур шатлык. Без монда тартылабыз. Эшлисе эшләребез бик күп, һәм башкарган эшләрне күреп шатланабыз, - диде ул. ТР Дәүләт Киңәшчесе, шулай ук, Болгар җирлегенең кыска гына вакыт эчендә ЮНЕСКО исемлегенә кертелүен дә ассызыклады. "Хәзер Болгар җире бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелде. Ул – киләчәк буыннарга калачак мирас", – диде М. Шәймиев.

Чыгышында ТРның беренче Президенты Болгар ислам академиясе хакында да сүз алып барды. Бәйрәмгә кадәр ул Болгар ислам академиясен гамәлгә куючылар белән очрашкан иде. "Бүген без академиянең тулы исемен сайладык, ул Болгар ислам академиясе дип аталачак. Әгәр дә РФ Президенты Владимир Путин һәм ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов соңгы елларда ярдәм итмәсә, бердәмлек һәм ислам академиясе хакында сөйләшү дә булмас иде, - диде Минтимер Шәймиев. Бәйрәмгә килгәндә исә, ул: "Кешеләргә җан азыгы кирәк. Мәүлидтә Пәйгамбәребезне зурлыйлар, аңа рәхмәт сүзләре әйтелә. Яхшы сүз – җан азыгы. Шунсыз җәмгыять була да алмый...", – дигән фикерен җиткерде.

ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин: "Бу бәйрәмне кайбер мөселманнар кире кага. Әмма ул чынлыкта да бар", - диде һәм моңа дәлилләр китерде. Шулай ук ул мөселманнарны Мәүлид бәйрәме белән котлады. Татарстан мөфтие дини бәйрәмнең югары дәрәҗәдә оештырылуын билгеләп үтте.

Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгать хәзрәт Таҗетдин да котлау сүзләрен җиткерде: "Бу изге һәм кадерле көн. Ул көнне Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм дөньяга килгән. Әлеге бәйрәм безне берләштерә, якынайта. Намаз укыган, ураза тоткан һәм вафат булуын көтеп яшәгән кеше генә иманлы дигән сүз түгел. Карагыз, бабаларыбыз нинди урын сайлаган. Алар яши дә, куана да белгән".

Быелгы Мәүлид ән-Нәби бәйрәме салават әйтү һәм намаз уку белән тәмамланды.

**TATAR-INFORM**

# Хәләл продукция нинди булырга тиеш?

**Соңгы вакытта хәләл кулланучыларда кош-кортны, терлекне кулдан һәм механик юл белән чалуга бәйле сораулар туа. Шәригать буенча аларның кайсысы дөрес? Бу мәсьәләгә Диния нәзарәте каршындагы "Хәләл" стандарт комитетының карашы нинди? Шушы сораулар белән без "Хәләл" стандарт комитетының экспертлар булеге җитәкчесе Фоат хәзрәт МӨХӘММӘТОВка мөрәҗәгать иттек.**

- Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте каршындагы "Хәләл" стандарт комитеты кошларны һәм терлекләрне бары тик кулдан чалуны гына дөрес дип таба. Хәнәфи мәзһәбенә караган шәригать белгечләре фикере дә шундый: ислам кануннары нигезендә кош-корт, мал фәкать кулдан чалынырга тиеш. Шәригать таләпләренә караган берничә кагыйдәне искә төшерик:

- чалучы балигълык яшенә җиткән, аек акыллы мөселман яки Китап әһеле (христиан, яһүд) булырга тиеш;
- чалу үткен пычак яисә башка әйбер белән башкарыла;
- чалучы чалыр алдыннан "бисмиллә" әйтә, ягъни Аллаһы Тәгаләнең исемен зикер итә. "Бисмиллә" һәр чалынучы малга әйтелә. Безгә бу хакта Изге Коръәннең "Әл-Әнгам" ("Терлекләр") сүрәсенең 119 нче, 121 нче, 138 нче, "Әл-Маидә" ("Аш табыны") сүрәсенең 4 нче аятьләре хәбәр итә. Бу уңайдан магнитофон язмаларын куллану ярамый. Әгәр чалучы мал чалганда "бисмиллә" әйтергә онытса, чалынган мал итен ашарга ярый. Әгәр инде белә торып әйтмәсә, чалынган итне ризыкка кулланырга ярамый.

Күрәбез: бу кагыйдәләрдә чалучыга ничек эш итәргә кирәклеге ачык күрсәтелә. Механик чалу вакытында исә бу кагыйдәләрне үтәп булмый. Механик пычак Аллаһы исемен зикер итә алмый. Автоматик пычак чалу башкарыла торган инструмент функциясен генә үти ала.

Шул ук вакытта мал чалу шәригать буенча да, физиологик һәм психологик яктан да катлаулы процесс булып тора. Тагын берничә мисал китерәбез:

- терлек алдында пычакны яисә башка чалу инструментын үткерләргә ярамый;
- малны үтми торган инструмент белән интектереп чалу тыела;
- тиресен тунауга мал җан биргәч кенә тотынырга кирәк;
- җаны чыкмыйча кошны кайнар суга салырга һәм йонын йолкырга ярамый. Бу эшләр чалынучы мал яки кош җан биргәннән соң гына башкарыла.

Дөрес чалынганда йоткылык, тын юлы, кан тамырлары киселә. Чалу җитез бер хәрәкәт белән эшләнә, аны сузарга ярамый. Бу таләпләрне беринди механизм үти алмый. Әгәр чалу дөрес булса, мал шунда ук аңын югалта, авыртуны тоймый, ә каны тулысынча агып бетә. Әгәр дөрес чалынмаса, мал интегүгә дучар ителә, каны чыгып бетмичә тәнендә кала, ә бу итнең тиз бозылуына, микроблар үрчүгә китерә. Шуңа күрә безнең Комитет сертификатлары нигезендә эшләүчеләрдә фәкать кулдан чалу гына кулланыла. Комитет хәләл ризык эшләп чыгаручы предприятиеләргә, шәхси эшмәкәрләргә бары тик кулдан чалынган хәләл ит белән генә эш итәргә тәкъдим итә.

Кайбер сертификат бирүче оешмалар механик чалуны да мөмкин дип саныйлар. Алар моны ничек дәлилләрдер – безгә билгеле түгел. Бәлкем, алар башка мәзһәбләр кагыйдәләре буенча эш итәләрдер? Сорау туа: хәләл җитештерүчеләрдән кемнәр механик чалуны куллана? Безгә әлегә бер җитештерүче билгеле. Ул – Белгород өлкәсенең "Приоскольe" фабрикасы. Бу компаниянең дилерларына һәм сатып алучыларына шуны җиткерәсе килә: ошбу фабрикада җитештерелгән тавык ите, фарш, башка ризыклар безнең Комитет сертификаты буенча эшләүчеләр тарафыннан кулланылмый. Форсаттан файдаланып, башка хәләл ризык җитештерүчеләрнең дә игътибарын моңа юнәлтәсе килә.

Хәләл продукциянең сертификатлары булырга тиеш. Ул Мәскәү, Татарстан, Башкортостан Комитетлары тарафыннан бирелергә мөмкин. Этикеткасына мәчет рәсеме төшерелгәнне яки "мөселманча" дип язылганны хәләл дип кабул итүчеләр бар, әмма һәр ризыкның сертификаты булырга тиеш. Җитештерүчеләр һәм эшмәкәрләр үз продукцияләрен хәләл маркасы астында чыгаралар икән, алар Кулланучыларны яклау Законының 10 маддәсе җаваплылыгында эш итәләр.

Продукциянең хәләллеген кем исбатлый ала? Әлбәттә, моңа хокукы булган органнар гына. Татарстанда мондый хокукка Диния нәзарәте каршындагы "Хәләл" стандарт комитеты ия.

# Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм – иң камил кеше

**Безнең эраның алтынчы гасырында бу дөньяга бөтен кешелек өчен үрнәк камил кеше җибәрелә – соңгы Пәйгамбәр Мөхәммәд галәйһиссәләм. Бөек Аллаһы изге Коръәндә җирдәге һәм ахирәттәге тормыш бәхетле булсын өчен барлык кешеләргә Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмгә ияреергә куша.**

Мөхәммәд галәйһиссәләм, пәйгамбәрләр имамы буларак, барлык пәйгамбәрләрнең иң матур сыйфатларын үзендә туплаган. Ул мул сулы елгалар койган диңгез кебек. Һәрбер кеше аның тормышын үзенә үрнәк итеп алырга мөмкин. Мөхәммәд галәйһиссәләм үзенең бер хәдисендә: "Мин күркәм әхлакны камилләштерү өчен җибәрелдем", – дип әйткән (Әхмәд бин Хәнбәл, Муснад). Аллаһы Раббыбыз да Коръән Кәримендә Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмне мактап: "Хакыйкатьтә, син – югары әхлак иясе", – дигән. ("Каләм" сүрәсе, 4нче аять).

Ул игелекле, итагатьле, шәфкатьле, миһербанлы, сабыр, киң күңелле, юмарт, ышанычлы, тыйнак була. Бу сыйфатлар Пәйгамбәребез галәйһиссәләмдә иң камил дәрәҗәдә була. Коръәндә әйтелгән: "Тәхкыйк, Аллаһы Рәсүлендә сезгә ияреергә тиешле булган күркәм холык вә яхшы сыйфатлар бардыр, Аллаһыдан савапны һәм ахирәттә җәннәтне өмет иткән хәлдә, Аллаһыны күп зикер итүче мөэминнәр өчен" ("Әхзаб" сүрәсе, 21нче аять).

Аллаһы илчесе галәйһиссәләмнең әхлак чыганагы – Коръән булган. Шуңа күрә: "Рәсүлебезнең холкы нинди иде соң?" - дигән сорауга Гайшә анабыз (Аллаһы аннан разый булса иде): "Аның холкы – Коръән иде", – дип җавап биргән. Ул Коръәни Кәрим тыйган нәрсәгә ачуланып караган һәм Коръәни Кәрим кушкан нәрсәдән канәгатьләнү тойган. Ул Аллаһыга ошамаган гамәл кылучыларны хөкем иткән һәм шелтәләгән. Рәсүлебез галәйһиссәләм Аллаһы риза булмаган нәрсәләр өчен генә ачуланган.

Аллаһы Рәсүле галәйһиссәләм югары дәрәҗәдә намуслы һәм ышанычлы, кешеләр белән мөнәсәбәттә йомшак һәм дустанә кеше булган. Ул әхлакый, саф фикер йөртергә яраткан. Аллаһы илчесе галәйһиссәләмгә тупаслык, әдәпсезлек һәм оятсызлык ят булган. Ул беркайчан да явызлыкка явызлык белән җавап бирмәгән, дошманнарын кичерә белгән. Әгәр кемдер аннан берәр нәрсә сораса, яки берәр нәрсә белән кызыксынса, Аллаһы илчесе галәйһиссәләм һәрвакыт йомшак һәм төпле итеп җавап биргән, тупас һәм ихтирамсыз бер сүз дә кулланмаган. Ул беркайчан да әңгәмәдәшен ярты сүздә бүлдермәгән. Әгәр берәрсенең сүзе чамадан чыкса, ул аны я кире каккан, я торып киткән.

Аллаһының Рәсүле галәйһиссәләм әйткән: "Миңа тәрбияне Аллаһы үзе бирде, һәм бу тәрбия нинди күркәм булды", – дигән (Суюти "Җәмигъ әс-сагыйрь"). Сәхабәләр Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең күркәм яшәү рәвешен, әдәбен күреп бик сокланганнар. Әнәс бин Мәлик (Аллаһы аннан разый булса иде) дигән сәхабә әйткән: "Мин Аллаһының Рәсүле гәләйһиссәләмгә ун ел хезмәт кылдым. Бер мәртәбә дә ямьсез сүз сөйләгәнен ишетмәдем. Беркайчан да: "Бу эшне ник болай эшләдең?" – дип ачуланганын күрмәдем", – дигән (Мөслим).

Аллаһы Рәсүле галәйһиссәләм күршеләрен хөрмәт иткән һәм кунакларын ихтирам белән кабул иткән. Аның Аллаһ өчен хезмәт итмәгән яки яхшы гамәл кылмаган бер генә минуты да булмаган. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм киләчәккә өмет белән караган, төшенкелеккә бирелүне яратмаган. Ул ике эшнең берсен башларга кирәк булганда, аларның иң файдалысын сайлаган. Ул бәлагә төшкәннәргә ярдәм итәргә һәм мәзлүмнәрне коткарырга яраткан.

Аллаһ илчесе галәйһиссәләм үзенең сәхабәләрен бик яраткан, алар белән еш киңәшләшкән һәм алар турында кайгырткан. Әгәр сәхабәләреннән берәрсе авырып китсә, ул аларның хәлен белергә бара торган булган. Әгәр берәрсе югалып торса, Пәйгамбәребез галәйһиссәләм аны эзләгән. Берәрсе вафат булса, аның хакына дога кылган. Ул һәрвакыт башкаларның гафу үтенүен кабул иткән, аның өчен көчле дә, көчсез дә үз хокукларында тигез булган. Сүз остасы буларак, Пәйгамбәребез галәйһиссәләм күп төрле гыйбрәтле хикәяләр һәм тарихлар сөйли торган булган. Ул һәрвакыт дөресен генә сөйләгән.

Аллаһы Рәсүле галәйһиссәләмнең тәрбиялелеге һәм әдәплелегенә килгәндә, ул сәхабәләренә бик мәрхәмәтле, хөрмәтле мөнәсәбәттә булган, кысан җирдә һәрвакыт башкаларга күбрәк урын калдырган. Берәрсен күрсә, ул аны һәрвакыт беренче булып сәламләгән.

Аллаһ илчесе галәйһиссәләм бик тыйнак булган. Кешеләр җыелган җиргә яки җыелышка килгәч, ул урын бар җиргә утырган һәм моның белән барысының да бертигез хокуклы икәнлеген ассызыклаган. Әңгәмәдәше белән утырганда беркайчан да аннан алда торып басмаган. Ашыккан вакытта һәрвакыт гафу үтенгән.

Пәйгамбәребез галәйһиссәләм беркайчан да ярлыларга фәкыйрьлекләре өчен җирәнеп карамаган, байлар алдында түбәнчелек күрсәтмәгән. Ул һәрвакыт иминлекне югары куйган. Ашаганда, әчкәндә уң кулын файдаланган, чөнки аңа Аллаһы шулай кушкан. Ул хуш исләрне яраткан: суган, сарымсак кебек начар ис таратучы нәрсәләрне сөймәгән. Аллаһы илчесе галәйһиссәләм үзенең сәхабәләреннән киеме белән дә, җыелышларда утырган урыны белән дә аерылып тормаган. Берәрсе килсә: "Әй сезнең кайсыгыз Мөхәммәд соң?" – дип сорый торган булган.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм киемнәрдән ашык сөягенә кадәр җитүче озын җилән киеп йөрергә яраткан. Кием-салымда да, ризыкта да бернинди артыклыкны кабул итмәгән. Башына чалма һәм башлык кия торган булган, ә уң кулының чәнчә бармагында көмеш балдагы булган.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтте: "Ий кешеләр, тәхкыйк, сезгә үз арагыздан пәйгамбәр килде, Аллаһыга карышуыгыз аңар авырдыр, сезнең иманга килүегез өчен ул бик тырышучы, мөэминнәргә шәфкатьледер" ("Тәүбә" сүрәсе, 128 нче аять).

"Күңелебездә Пәйгамбәребезгә мәхәббәт бармы?" - дигән сорау бирәсе килә. Ни өчен без бәхетсез соң? Бездән Раббыбыз канәгатьме? Тормышыбыз кая бара? Без кешеләр белән нинди мөнәсәбәттә? Без аларга ярдәм итәбезме, аларны аңлыйбызмы? Яисә без үзебез турында гына уйлыйбызмы?

Сорауларга җавап табыйк та, тормышыбызны үзгәртик, җәмәгать.

## Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмгә карата булган әдәп

Сәхабәләр сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәләмгә карата һәрвакыт әдәпле булганнар. Алар: "Без Аллаһының Рәсүле галәйһиссәләмнең нәсыйхәтләрен тыңлаганда күңелләребез Раббыбыз Аллаһыга һәм Аның Пәйгамбәре Мөхәммәд галәйһиссәләмгә карата мәхәббәт һәм әдәп белән тула иде, әйтерсең лә башларыбызга кошлар кунган һәм әгәр без хәрәкәтләнсәк, ул кошлар очып китәр иде", – дигән (Ибн Мәҗәһ).

Сәхабәләр Пәйгамбәребез галәйһиссәләмгә сорау бирергә һәм аның күзләренә туры карарга да оялганнар. Хәтта Аллаһының Рәсүле Мөхәммәд галәйһиссәләм янәшәсендә еш булган сәхабәләр дә, аңа карата әдәп саклап, аның күзләренә ачык карый алмаганнар. Имам Тирмизи (Аллаһының рәхмәтендә булсын) хәбәр иткәнчә, бары тик Әбү Бәкер белән Гомәр (Аллаһы алардан разый булсын) генә аның күзләренә карап сөйләшә алганнар, калган сәхабәләр Пәйгамбәребез галәйһиссәләм белән сөйләшкәндә күзләрен читкә алганнар.

Гамр бин Гас (Аллаһы аннан разый булсын) үз гомеренең соңгы минутларында сөйләгән: "Мин озак вакыт Пәйгамбәребез галәйһиссәләм янында тордым, ләкин аны бик хөрмәт иткәнгә һәм оялганга күрә, башымны күтәреп аңа озак карый алмадым. Әгәр бүген миннән аның йөзе турында сорасалар, ышаныгыз миңа, сөйләп бирә алмас идем", – дигән (Мөслим).

Коръәндә пәйгамбәрләрнең исемнәре китерелгән булса да, Аллаһы Тәгалә соңгы пәйгамбәргә бер тапкыр да "Йә Мөхәммәд" дип мөрәҗәгать итмәде. Аллаһы Раббыбыз аңа "Йә нәби", "Йә Рәсүл", дип эндәште. Аллаһы Тәгалә барлык мөселманнарга Пәйгамбәребез галәйһиссәләмгә карата әдәпле булырга боерды. Бу турыда "Нур" сүрәсенең 63нче аятендә әйтелгән: "Бер-берегезне чакырган кебек, Пәйгамбәрне дә шулай чакырмагыз. Арагыздан бәгъзеләрегез юкны сылтау итеп, мыштым гына (рөхсәтсез) качып киткәннәрне Аллаһы белә. Аң булыгыз, Аның әмереннән качып китеп (бу дөньяда) үзегезгә фетнәбәла чакыра күрмәгез яки (ахирәттә) андыйларга бик хәтәр җәза китереп сугуы бар".

Ибн Габбас (Аллаһ аннан разый булсын) бу аять турында болай дигән: "Кешеләр Аллаһның Рәсүле галәйһиссәләмгә "Йә Мөхәммәд", "Йә Әбулкасыйм" дип эндәшәләр иде. Аллаһы Тәгалә аның дәрәҗәсен күтәрер өчен, алай дип әйтүне тыйды, шуннан соң кешеләр Пәйгамбәребез галәйһиссәләмгә "Йә нәби", "Йә Рәсүл", дип мөрәҗәгать итә башладылар.

Бер солтан тормышыннан мисал китерәм. Габделгазиз исемле солтан авырып, урында яткан вакытта, аңа нурлы Мәдинә шәһәреннән хәбәр килә. Ул үз ярдәмчеләрен чакыртып: "Миңа аякка басарга ярдәм итегез. Мәдинә шәһәреннән килгән хәбәрне басып тыңлау тиешле. Аллаһның Рәсүле галәйһиссәләмнең күршеләрен ятып тыңлау ярамас", – дип әйткән. Нурлы Мәдинәдән хат килгән саен, бу солтан тәһарәтен яңартып, кулына хат алып, аны үбеп, маңгаена куеп: "Бу хатта нурлы Мәдинәнең тузаны", - дигән һәм шуннан соң гына хатны укыган.

**Нияз хәзрәт САБИРОВ, ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе**

# Һәр мөселман бәндәсе белергә тиешле мәгълүмат

**Рәсүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) фил елы дип атала торган елны, рабигыльәүвәл аеның 12 нче көнендә дөньяга килә.**

Туган көне дүшәмбе була. Шуңа күрә Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән халык аның дүшәмбе көнне тота торган нәфел уразасы турында сорагач, ул (салләллаһу галәйһи вә сәлләм): "Ул көнне мин туганмын һәм үземә Коръән иңә башлады", - дип җавап биргән.

Без, мөселманнар Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең туган көнен яки Мәүлид-шәрифен елга бер мәртәбә үткәреп алсак, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе, Аллаһы Тәгаләгә шөкерана йөзеннән, туган көнен олылап, уразалар тотып, елына аны илле мәртәбә үткәргән, дип әйтү дөрес булыр!

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм туар алдыннан:

- төнлә Кәгъбәтуллаһ эчендәге потлар йөзтүбән авалар;
- Фарсы (Иран) падишаһы сараеның тора торган җире хәрәкәткә килеп йөри башлый, 14 матча баганасы ава;
- фарсыларның моңа кадәр бер дә сүнмәгән "изге" утлары сүнә;
- Сәвәһ исемле күл корып куя.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм корсакта булган чакта аның атасы вафат була. Алты яшенә җиткәч, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әнисе Әминә абыстай вафат булган. Шуннан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне бабасы Габделмотталиб тәрбия кыла.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә 8 яшь 2 ай 10 көн булганда бабасы да вафат була һәм аны ата ягыннан бертуган булган Әбү Талиб агасы үз карамагына ала.

12 яшь 2 ай 10 көндә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм агасы Әбү Талиб белән бергәләшеп Шәм-шәриф сәфәренә чыгалар. Шәмшәриф хәзерге Сүрия җирләре була. Бусра исемле шәһәргә җиткәч, аларны дөньядан ваз кичкән, исе китмәгән, Бәхирә исемле галим карт очрата. Ахырзаман пәйгамбәренең китапларда тасвирланган сыйфаты-кыяфәте буенча танып, аны (салләллаһу галәйһи вә сәлләмне) кулыннан ала һәм: "Бу – галәмнәрнең Тәрбиячесенең Рәсүле. Аллаһы Тәгалә аны галәмнәргә илаһи мәрхәмәтен ачыклау ягыннан җибәргән. Бу урыннан кузгалгач, аңа сәҗдә кылмый торган таш һәм агач калмас. Ташлар-агачлар исә Пәйгамбәр каршында гына сәҗдә кылырлар. Без (әһле Китап) аның турында шундый кыяфәттә тасвирланган килеш Китапларыбызда мәгълүмат табабыз", - дип әйтә. "Әгәр син аның белән бу урыннан Шәм-шәрифкә кузгалсаң, яһүдләр аны үтерерләр", - дип кисәткәч, хәзрәти Әбү Талиб һәм яшь Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәгә кайтыр юлга чыгалар.

Икенче мәртәбә хәзрәти Рәсүл Әкрәм салләллаһу галәйһи вә сәлләм Шәм-шәрифкә хәзрәте Хәдичә радыяллаһу ганһәнең хезмәтче малае Мәйсәрә белән бергә



сәүдә эшләре белән юл тоткан. Бусра шәһәренә кергәч, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Бәхирә картның тора торган урыны янындагы бер агачның шәүләсендә ял итә. Бәхирә карт бу хәлне күреп: "Бу агач шәүләсендә Пәйгамбәрдән башка беркем дә ял итмәс!" – дип икърар кылган.

Мәйсәрә исә өйлә белән икенде арасында һәм эсселек арткан саен аның өстендә ике фәрештә иңеп, канатлары белән шәүлә биреп торалар иде, диеп сөйләгән.

Шушы сәфәрдән кайткач, Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәте Хәдичә радыяллаһу ганһә белән никахлаша. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә бу вакытта 25 яшь тә 2 ай һәм 10 көн була.

Утыз биш яшь тулгач, Рәсүл Әкрәм (салләллаһу галәйһи вә сәлләм Кәгъбәтуллаһны төзәтү-яңарту эшләрендә катнаша һәм мөбарәк куллары белән Кара ташны махсус урынына урнаштыра.

40 яшь тулып 1 көн узгач, Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Хира мәгарәсе эчендә булганда аның янына Аллаһы Тәгаләнең әмере белән Җәбраил фәрештә галәйһиссәлам килә. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең пәйгамбәрлеге рамазан шәриф аенда башлана. Бу көн – дүшәмбе көне була. Шуннан соң 3 ел буена Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның әһле-бәйте кирам Мәккә кәферләренең дошманлыгы вә чолганышында үткәрәләр. 3 ел буена аралашу, туганлашу, алыш-бирешләр туктала. Бу гаять авыр чор тәмамланган заманда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә 49 яшь була. Шуннан соң 8 ай һәм 3 атна вакыт узгач, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең абыйсы, хәзрәте Әбү Талиб вафат була, аннан соң 3 көн үтә дә хәзрәте Хәдичә абыстай радыяллаһу ганһә вафат була.

50 яшь тулып 3 ай узгач, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына Нәсыйбиннән җеннәр килеп, ислам динен кабул итәләр.

51 яшь тулып 9 ай үткәч, ул (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) Зәмзәм суы белән Мәкаме Ибраһим арасында булган урыннан күккә күтәрелеп, Кодыс-шәрифкә (Иерусалимга) сәяхәт кыла. Бу сәяхәт әл-Исра дип атала.

Мәккә-и Мөкәррәмәдән күтәрелеп, Рәсүле Мөхтәрәм салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең фәрештәнең хөснәнәсыйхәте белән киләчәктә яшәячәк Тыйбәһ (Таййибәһ) шәһәренә, шуннан Муса галәйһиссәламнең Аллаһы Тәгаләдән Тәүрат бәхетенә ирешкән Сәйнә тавына, шуннан соң Гайсә галәйһиссәлам туган Бәйт Ләхем шәһәренә төшеп, һәркайсында икешәр рәкәгать тәхиййәт намазларын укуы мәгълүм.

Кодыс-шәрифтә Рәсүл Әкрәм салләллаһу галәйһи вә сәлләм әл-Борак исемле бер гаҗәеп хайван өстенә утырып күккә күтәрелә. Җиденче кат күккә күтәрелгәч, хәтта Җәбраил галәйһиссәлам җитә алмаган урынга җитеп, Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтләре белән сохбәт кыла. Шунда илаһи бүләкләргә ирешә, өммәтенә намаз фарыз ителә. Сәяхәтнең бу өлеше әл-Мигъраҗ дип атала.

53 яшькә җиткәч, Рәсүл Әкрәм салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккә-и Мөкәррәмәдән Мәдинә-и Мөнәввәрәгә һиҗрәт кыла. Бу вакыйга рабигыльәүвәл аеның 21-22 көннәрендә, дүшәмбе көнне була. Мәдинә-и Мөнәвварәдә Рәсүл Әкрәм салләллаһу галәйһи вә сәлләм 10 ел яши һәм шунда җан тәслим кыла.

**Фәрид хәзрәт СӘЛМАНның "Пәйгамбәр-намә" китабыннан**

# Мәүлид кичәсенең фазыйләтләре

**Хәзрәти Мәгъруф Әл-Кәрхый әйткәнчә (Аллаһы аны үз рәхмәтеннән аермасын): "Кем дә булса Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) Мәүлиден укытырга ризык хәзерләсә һәм Мәүлидне хөрмәтләп, туган, дус-ишләрен җыйса, өен ут белән яктыртса, яңа киемен киеп, хуш исләр, хуш ислемайлар белән сөртенсә, Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә ул бәндәне Пәйгамбәрләр белән бер төркемдә булдырыр һәм (аның урыны) югары Гыйллийиндә (җиденче күктә) булыр".**

Заманының бердәнбере, гасырында берүзе (сыйфатларына карата) булучы Имам Фәхретдин Әр-Рази болай әйткән: "Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) Мәүлиден тоз, яисә бодай, яки башка бер ризык өстенә укыса шул ризыкка бәрәкәт иңәр. Инде су өстенә Мәүлид укылганнан соң, ул суны эчүченең кальбенә (йөрәгенә) мең нур һәм шифа керер, мең явызлык һәм авыру чыгып китәр. Мондый йөрәк, башка йөрәкләр үләчәк көнне үлмәячәкдер".

Галимнәрнең солтаны Имам Җәләледдин Әс-Суйүтий (Аллаһы аны үз рәхмәтеннән аермасын) болай дип әйткән: "Берәр йортта, яисә мәчеттә, яисә берәр мәхәлләдә (кварталда) Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) Мәүлиде укылса ул йортның, яисә мәчетнең, яки мәхәлләнең тирә-якларын фәрештәләр чорнап алалар һәм шушы урынның халкына фәрештәләр салават әйтеп торырлар һәм барысына да Аллаһы Тәгалә тарафыннан мәрхәмәт һәм Аллаһының разыйлыгы насыйп булыр. Җәбраил, Микаил, Исрафил һәм Газраил (галәйһимис-сәләм) фәрештәләр исә Мәүлид укуга сәбәпче кешегә үзләре салават әйтерләр". Һәм аның хәбәр итүенчә: "Әгәр берәр мөселманның өендә Мәүлид укылса, ул өйгә Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән корылык тимәс, вәба (чума) авыруы кермәс, ут тимәс, су (ташкын) тимәс, бәла-афәтләр, нәфрәт, хәсет, явыз күз, караклардан имин булыр. Әгәр Мәүлид укучы бәндә вафат булса, Аллаһы Тәгалә Мөнкир вә Нәкир сорауларына җавап бирүне җиңеләйтер, һәм ул бәндә кодрәтле Аллаһы Тәгаләнең хаклык урынында булыр".

# Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышы (сира)

## Аның тышкы кыяфәте

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм күркәм кыяфәтле кеше булган. Аның (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) буе артык биек тә, кыска да булмаган. Ләкин кешеләр арасында ул (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) биегрәк булып күренгән, киң җилкәле, көчле, нык туры бәдәнле булган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең калак сөякләре арасында пәйгамбәрлек тамгасы төшкән булган. Аның (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) тән тиресе аксыл, чәчләре дулкынлы кара, сакалы кара һәм куе, уч төбе киңлеге озынлыгында булган, тешләре тигез һәм ялтырап торган. Сәхабәләре тасвирлавынча, аның (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) йөзе башкаларныкыннан ягымлырак һәм сөйкемлелеге белән аерылган. Аллаһы илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм, ак төстәге тыйнак һәм җайлы киемнәр, ә башына чалма кия торган булган. Хәтта ислемайлар кулланмаган очракта да, аннан (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) һәрвакыт хуш ис килеп торган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән кул биреп күрешкән кешеләр, аннан аерылып китеп күпмедер вакыт узганнан соң да, ул хуш исне тойганнар.

## Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең көндәлек тормышта үз-үзен тоту үзенчәлекләре

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөйләме тәэсирле һәм ачык булган. Ул (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) сүзләрне аңлаешлы итеп әйткән, кирәк булса, кинаяле рәвештә дә аңлаткан, беркайчан да сүгенү сүзләрен телгә алмаган, сөйләүчене бүлдермәгән һәм буш сүз сөйләмәгән, очраткан кешесен беренче булып сәламләгән, көлүен сирәк көлсә дә, бик еш елмайган. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дөньявилыктан читләшкән, көнкүрештә бик тыйнак булган. Мөселманнарның җитәкчесе булуына карамастан, беркайчан да патшалар кебек яшәмәгән: киемнәрен дә үзе ямаган, бернинди урын-җирсез чыптага гына ятып йоклаган вакытлары булган, ашау-эчүдә дә урталыкны саклаган, беркайчан да артыгын ашамаган һәм иярченнәрен дә шуңа өндәгән, ризыкка беркайчан да канәгатьсезлеген белдермәгән: ошамаса, ашамыйча калдырган гына. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм авыруларның хәлен белергә гадәтләнгән була. Үзен (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) кунакка чакыра калсалар, байларның да, ярлыларның да чакыруларын бертигез кабул иткән.

## Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әхлагы

Аллаһы Тәгаләнең Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм Коръәни Кәримдә язылганнарның тере гәүдәләнеше булган. Ул (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) барлык кешеләрдән дә юмарт булган, мохтаҗларга үз милкеннән өлеш чыгарган, берәүнең дә үтенечен кире какмаган, кыю һәм батыр булган, сугышка беренче сафта кергән, катлаулы хәлләрдә, вәсвәсәгә бирелмичә, Аллаһы Тәгаләнең ярдәменә тапшырылган, мөселманнар өчен иң авыр чорларда да исламга өндәвен туктатмаган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең ачуы үзе өчен үпкәләгәннән түгел, бары Аллаһы Тәгалә хакына гына, хаклыкны бозганга чыга торган булган. Күп очракларда, гаепле кешене җәзалау мөмкинлеге булганда да, ул гафу иткән.

## Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең табынуы

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә дөньялыкта ук җәннәт вәгъдә ителсә дә, Аллаһы Тәгаләгә табынуда ул барлык кешеләрдән дә күбрәк тырыша торган була. Төнге намазлардан аяклары шешенгәч, аннан (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) ни өчен бу кадәр тырышуын сораганнар. Чөнки ул (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) Аллаһы Тәгаләнең ярлыкануына инде ирешкән бит. Шунда Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: “Аллаһының мәрхәмәте өчен мин шөкер итәргә тиеш түгелмени?” Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәр төн саен тәһәҗҗүд намазы укыган, Аллаһы Тәгаләне даими зикер иткән, еш кына ураза тоткан. Шулай да, ул (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) мөселманнарны табынуда чаманы арттырудан кисәткән һәм үзенең үрнәгендә вакытывакыты белән уразада булып, төннең бер өлешен намазда үткәреп, икенче өлешен ял итәргә кирәклеген әйткән.

Аллаһы Тәгаләнең Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләмне ярату ислам диненең аерылгысыз бер өлеше булып тора. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышын һәм сыйфатларын өйрәнеп, иманлы кеше үзендә шушы хисләрне тәрбияләргә тиеш.

## Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең балалары

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең барлыгы җиде баласы: дүрт кызы – Зәйнәб, Рокыя, Өммөкөлсем, Фатыйма һәм өч углы – Касыйм, Габдуллаһ, Ибраһим булган.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм балаларын бик яраткан һәм аларга карата бик ягымлы, йомшак күңелле һәм иркәләүчән булган.

Углы Ибраһимнан башка балаларын өммәт анасы, Аллаһы Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Хәдичә (Аллаһы аннан разый булсын ) исемле хатыны тапкан.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең беренче углы Касыйм Изге Мәккәдә туган. Ул сабый чагында ук үлгән. Аннан соң Зәйнәб туган. Ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең туганнан туганына кияүгә чыгып, балалар да тапкан була. Ләкин яшьли үлеп китә. Хәдичә белән Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өченче баласы Рокыя булган. Үсеп җиткәч, аны Госман, Аллаһы аннан разый булсын, исемле сәхабәгә кияүгә бирәләр. Рокыя да озын гомерле булмый: яшь чагында ук авырый башлап, Бәдер сугышы вакытында үлеп китә. Дүртенче кызлары – Фатыйма Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең туганнан туганы Галигә кияүгә чыга, аларның алты баласы туа. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәселе боларның олы угыллары Хәсән белән Хөсәеннән дәвам иттерелә. Бүгенге көндә дә нәсел җепләре Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә үк барып тоташкан кешеләр яши. Өммекөлсем атасының Пәйгамбәрлек вазыйфалары башланганнан соң туган кыз. Апасы Рокыя вафатыннан соң, ул Госманга кияүгә чыга. Ләкин Өммекөлсем дә озын гомерле булмый. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең икенче углы һәм алтынчы баласы Габдуллаһ та ислам чорында дөньяга килә, әмма балачакта ук үлә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең углы Ибраһимны исә Мәрьям тудырган. Ул үзе Мисырда туып, шундагы хөкемдарның сарай даирәсендә кол хезмәтче булган. Мисыр хөкемдары аны кол рәвешендә Аллаһы Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә бүләк иткәч, ул исламны кабул итә һәм коллыктан азат ителә. Аллаһы Тәгалә Мәрьямгә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән угыл табырга насыйп итә. Мәрьям үлгәннән соң, җеназа намазын диндарлыгы белән танылган Гомәр халифә, Аллаһы аннан разый булсын, үзе укый.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өчен угылының тууы гадәттән тыш сөенечле вакыйга була. Тик, шулай да, Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бу угылын да озын гомерле итми: Ибраһим балачакта ук үлә. Аллаһы Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм углының вафатын бик авыр кичерә, үзе аңа җеназа намазы укый һәм күмә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышындагы шушы вакыйгадан без балалары үлгән ата-аналарга елау һәм кайгыруның тыелмаган булуын аңлыйбыз. Чөнки кеше кайгы-хәсрәт һәм сагыш кебек хис-кичерешләрне тыя алмый. Шулай да такмаклап һәм кычкырып еларга ярамый. Аллаһы Тәгаләнең ихтыяры белән ризалашырга һәм баланың үлгәннән соң җәннәткә әләгүенә ышанырга кирәк. Аллаһы Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә, балигъ булганчыга кадәр үлгән балалары ата-аналарын Кыямәт көнендә үзләре белән җәннәткә алып керәчәк, дип әйтеп калдырган. Шуңа күрә Аллаһы кушуы белән мондый кайгы-хәсрәтне кичергән ата-аналарга савапның иң олысы насыйп ителә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Фатыймадан башка балалары барысы да ул үзе исән чакта ук вафат булганнар.

## Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте

Сөннәт – ул Аллаһы Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең гамәлләре, сөйләгәннәре һәм хуплаганнары, ислам дине йолаларының гамәлдә ничек үтәлүен аңлатулары. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бөтен кешелек өчен үрнәк булып тора, шуңа күрә мөселманнар аңа, салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, бар яктан да: Аллаһыга табынуда да, холык-фигыльләре, гадәтләре, тышкы кыяфәтләре белән дә охшарга тырышалар. Мөселманнар өзелмәс чылбыр буенча Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үзеннән килеп ирешкәннәрне генә гамәлдә кулланалар. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышына кагылышлы барлык мәгълүмат та җентекләп тикшерелгән һәм сакланган.

Пәйгамбәрләр - үзенчәлекле кешеләр: Аллаһы Тәгалә аларны барлык гөнаһлардан да саклый. Шуңа күрә иманлы кешеләр, аларның эш-гамәлләрен диннең бер өлеше буларак кабул итеп, үзләренә үрнәк итә алалар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтенә ияре аны (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) яратуының чаткысы. Ә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә мәхәббәт аны кешеләргә җибәргән Аллаһы Тәгаләгә мәхәббәтне күздә тота.

Коръәни Кәримдә болай язылган: “Әй Мөхәммәд галәйһи вә сәлләм әйт: “Әгәр Аллаһыны сөяр булсагыз, миңа иярегез. Миңа иярсәгез, Аллаһы сезне сөяр һәм гөнаһларыгызны ярлыкар. Тәүбә итеп, Аллаһы юлына керсәгез, Ул, әлбәттә, ярлыкаучы һәм рәхимле” (3 нче “Әли-Гыймран” сүрәсе, 31 нче аять).

## Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәләре

Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләм: "Иң яхшы буын – безнең буын, аннары – бездән соңгы буын, аннары – алардан соң килүчеләр", - дип әйткән. Икенче төрле әйтсәк, сәхабәләр буыны – иң яхшы буын.

Бу кешеләр Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләмне үз күзләре белән күргәннәр, аңа ярдәм иткәннәр, беренчеләрдән булып аның пәйгамбәрлеген кабул иткәннәр. Без аларның барысын да ихтирам итәбез һәм мөселманнардан саныйбыз.

Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләмнең вафатыннан соң, хәлифәлек, ягъни ислам дәүләте белән идарә итү башта Әбү Бәкер әс-Ситдыйк, аннары – Гомәр ибн Хәттаб, аннан соң - Госман ибн Гәффан, Гали ибн Әбү Талиб, Аллаһы алардан разый булсын, кулларына күчә. Шушы дүрт хөкемдарны тугрылыклы хәлифәләр дип йөртәләр.

Әбү Бәкер әс-Ситдыйк, Аллаһы аннан разый булсын, ислам динен кабул иткәнче үк күп кенә күркәм сыйфатлары белән аерылып торган. Мәсәлән, ул беркайчан да хәмер эчмәгән. Әбү Бәкер, Аллаһы аннан разый булсын, исламны кабул иткән беренче ирекле (кол түгел) ир-ат булган.

Әбү Бәкер, Аллаһы аннан разый булсын, ислам җәмәгатьчелеген нык кайгырткан. Бер гыйбадәтендә ул: "Әй, Аллаһы! Мәңгелек дөньяда минем гәүдәмне тәмугны тутырырлык итеп зурайт та, башкаларга анда урын калмасын, барлык колларың урынына анда мин генә яныйм," – дип сораган.

Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләм: "Өч йөз алтмыш күркәм сыйфат бар", - дигән. Әбү Бәкер, Аллаһы аннан разый булсын: "Әй, Аллаһы Илчесе! Миндә аларның кайсы да булса бармы?", - дип сораган. Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләм: "Әй, Әбү Бәкер! Аларның барысы да сиңа хас", - дигән.

Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләм үзе авырганда имам итеп Әбү Бәкерне, Аллаһы аннан разый булсын, билгели торган булган. Мөхәммәд саллəллаһу галәйһи вә сәлләмнең вафатыннан соң, Әбү Бәкер, Аллаһы аннан разый булсын, хәлифәлек белән ике ел дәвамында идарә итә. Ул һиҗри ел исәбе белән 13 нче елда үлгән.

Гомәр ибн Хәттаб, Аллаһы аннан разый булсын, исән чакларында ук җәннәтле булулары мәгълүм булган сәхабәләрдән санала. Шуңа да карамастан, Гомәр, Аллаһы аннан разый булсын, тәмугтан курка торган булган. Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәсе Хөзәйфәгә икейөзле кешеләрне, монафыйкларны ачыкларга ярдәм итә торган гыйлемнәрне өйрәткән. Гомәр, Аллаһы аннан разый булсын, көн саен Хөзәйфәдән, үзендә монафыйклык чагылышлары күренмиме, дип сорый торган булган. Хөзәйфә исә, Гомәрнең тәкъвалыгына гаҗәпләнеп, елый-елый, аның монафыйк булмавын сөйләгән. Ә Гомәр, Аллаһы аннан разый булсын, Хөзәйфәне, үзен кызганып елый дип уйлап, үзе дә аның белән елаган.

Гомәр, Аллаһы аннан разый булсын, икенче тугрылыклы хәлифә булган. Аны "әмир әл-мөэминин" (мөселманнарның хакиме) дип атаганнар. Гомәр идарә иткән чорда хәлифәлек бик нык зурайган: ул Шәм (бүгенге Сүрия, Иордания, Палестина һәм Ливан җирләре), Мисыр, Гыйрак, Константинополь, Гарәп ярымутравы, Әзәрбәйҗан, Бәлх, Бохара, Сәмәрканд, Иран, Кече Азияне яулап ала.

Гомәр ибн Хәттаб, Аллаһы аннан разый булсын, һиҗри ел исәбе белән 23 нче елда вафат була: аны утка табынучы кол үтерә.

Госман ибн Гәффан, Аллаһы аннан разый булсын, исламга Әбү Бәкер, Аллаһы аннан разый булсын, өндәве белән килә: Әбү Бәкер аңа дөрес динне аңлатып бирә. Госман тышкы кыяфәте белән пәйгамбәр Ибраһим галәйһиссәләмгә охшаган була. Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләмнең ике кызы: Рокыя белән Өммөкөлсемгә никахлашканлыгы сәбәпле, аны "Зу-н-Нурәйн" (ике балкыш, нур иясе) дип атаганнар.

Госман, Аллаһы аннан разый булсын, төннәрен гыйбадәт кылып, көндезләрен уразада үткәрә торган булган. Серкә һәм зәйтүн җимешләре генә ашап яшәгән. Сугыш вакытында мөселманнар ачлыктан тилмергәндә, ул бөтен гаскәргә җитәрлек азык сатып ала.

Госман ибн Гәффан өченче тугрылыклы хәлифә булып, 12 ел идарә итә. Һиҗри ел исәбе белән 35 нче елда Коръән укып утырган җирендә, "Аллаһы сезнең өчен җитеш, Ул барын да ишетә һәм белә", дигән аятькә җиткәч, үтерелә.

Гали ибн Әбү Талиб, Аллаһы аннан разый булсын, исламны кабул иткән беренче бала була. Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләм, атасы Әбү Талибкә ярдәм итү максатыннан, аны тәрбиягә алган була. Мөхәммәд саллəллаһу галәйһи вә сәлләм Галине, Аллаһы аннан разый булсын, чын мөселманнарның имамы һәм юлдан язганнарны тугры юлга өндәүче, дип атый торган булган. Ибн Габбас тапшырганнар буенча, Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләм Галигә, Аллаһы аннан разый булсын,: "Син бу дөньяда да, мәңгелектә дә җитәкче. Сине яраткан - мине дә ярата, сиңа нәфрәтле – ул миңа да нәфрәтле", - дип әйткән.

Гали, Аллаһы аннан разый булсын, бик акыллы кеше һәм бөек галим булган. Кыюлыгы өчен аны Әсәдуллаһ (Аллаһы арысланы) дип атаганнар. Ул Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләмнең кызы Фатыймага өйләнгән булган.

Гали, Аллаһы аннан разый булсын, дүртенче тугрылыклы хәлифә була. Ул һиҗри ел исәбе белән 40 нчы елда үтерелә. Аны тәнлә яшерен рәвештә күмәләр, чөнки дошманнары аның каберен мәсхәрәләргә мөмкин, дип шикләнгәннәр.

**"Хозур" нәшрият йортында басылып чыккан "Ислам турында сөйләшик" энциклопедиясеннән алынды "Хозур" нәшрият йортында дөнья күргән китапларны Казанның Тукай урамында, 3 нче йортта урнашкан кибеттән сатып алырга була. Белешмәләр өчен телефон: 8 (843) 202 07 74.**

# МӘҮЛИД

**Ислам дине тотучыларның дини бәйрәмнәре шактый. Аларның кайберләре бәйрәм, икенчеләре – кичә, өченчеләре – көн дип йөртелә.**

Мөселманнарда иң олы бәйрәмнәр: Ураза, Корбан һәм Мәүлид бәйрәмнәре.

Мәүлид – Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) туган көне һәм шул вакытта үткәрелә торган бәйрәм.



Мәүлид – гарәпчәдән "туу" дигәнне аңлата. Ул – мөселманнарның зур бәйрәмнәреннән берсе булган Мәүлид кичәсе. Икенче төрле аны Мәүлид ән-Нәби, ягъни "Пәйгамбәрнең тууы" дип тә йөртәләр. Әлеге көн, бөтен дөнья мөселманнарының дөнья вә ахирәт сәгадәтләренә сәбәп булган Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) туган көне булу сәбәпле, мөбарәк көн исәпләнә. Бу көнне мәчетләрдә вәгазьләр сөйләнә.

Бер мөнәҗәттә мондый юллар бар:

*И, кардәшләр, сөенеч безгә*
*Изге Мәүлид ае туды.*
*Шатлык булсын барчабызга*
*Изге Мәүлид ае туды.*

Мәүлид аенда татар халкы яшәгән төбәкләрдә мәчетләрдә генә түгел, өйләрдә дә Мәүлид укыту, Мәүлид ашы үткәрү йолалары башкарылып килә. Иң әүвәл – салават, аннан соң зикер әйтәләр. Татар халкының җирле үзенчәлекләрен, телне һәм йолаларны, гореф-гадәтләрне өйрәнү экспедицияләрендә йөргәндә безгә күп кенә авылларда бәйрәм үткәрүнең үзенә хас якларын язып алу да насыйп булды. Мәсәлән, Себердә – Тубыл-Иртыш якларындагы Абаул дигән авылда Мәүлид мәҗлесендә, күмәкләшеп, "Сөембикә" мөнәҗәтен әйтәләр:

*Сөембикә, шатлан бүген,*
*Шатлана торган көнең.*
*Чөнки хәзрәте Мөхәммәд*
*Дөньяга туган бүген.*

Әстерхан өлкәсенең Приволжский районы Килинчи (Киләче) авылында Мәүлид бәйрәмен бик зурлап, мәчеттә күмәк табын ясап үткәрүне күреп кайткан идек. Монда хатын-кызлар, өлкән апалар бәйрәмчә киенеп, һәркайсы шул якларга хас булган бәйрәм ашларын пешереп алып килә. Без әлеге мәкаләбездә шушы авылдан алып кайткан язмаларыбызны, Нәсимә абыстай һәм өлкән хатын-кызлар сөйләгән мәгълүматларны китерәбез.

– Менә Мәүлид аенда матур итеп бәйрәмчәйгә җыелдык.

– Идәнгә тәстәрхан җәеп, түфәкмендәрләргә тезелеп утырып, бәйрәмашлардан авыз иттек.

– Тәстәрханыбызда бәйрәмебезне сыйлап алып килгән, кардәшләребез үзләре пешергән ашлар тезеп салынган.

– Менә Пәйгамбәребезнең яраткан ризыгы хәлвә (монда һәм алга таба нинди дә булса татлы ризык күз алдында тотыла; әйтик, милли ризыкларыбыздан чәк-чәкне дә шуңа кертеп карарга була. – **ред.**). Аны Мөслихә тәтәбез пешереп китерә ел да.

– Менә кыздырмыш (майда пешерелгән күмәч), үзем пешердем.

– Менә бавырсаклар, бәлешләр, кәнфитләр. Бавырсакларны тәстерханга чәчеп салабыз. Һәркем авыз итсен.

– Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) туган көнендә Коръән укыткан кеше Мәүлид аена хәлвә катыра. Болай башка вакытларда инде кеше теләсә генә катыра хәлвәне, теләмәсә, юк. Мәүлид аенда хәлвә ясарга тырышалар, ул Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) яраткан ризыгы булган. Шуның өчен хәлвә белән авыз итәләр.

*Чын күңелдән тыңласаң,*
*кил Мәүлидкә,*
*Укыйлар Мәүлидтә махсус касыйдә.*
*Сират кичмәгә эстәсәң,*
*Мәүлидкә кил,*
*Җәннәт эстәр булсаң, ашыгып,*
*Мәүлидкә кил.*

Ошбу укыган Мәүлид догасының савабын барча өммәтләренә насыйп әйләсәң иде.

Ошбу укыган Мәүлид догалары Кыямәт көне кояшыннан күләгә булсын, Кыямәтнең авыр сәгатендә шәфәгать булсын.

Яраббым, шушы Мәүлид аенда Мөхәммәд Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) туган көнен котлап, шушы дин мәҗлескә, бәйрәмчәйгә җыелган дин кардәшләребез укыган намазлар, хәтбәләрнең әҗер-савабын биргәй идең.

Мәүлид айларында шушылай итеп утырмага, намазларыбызны укымага насыйп ит, Ярабби!

**Флёра БАЯЗИТОВА,**
**филология фәннәре докторы**
**(dumrt.ru сайтыннан)**

# “Мөхәммәд”
## (салләллаһу галәйһи вә сәлләм)

### ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗНЕҢ ТУУЫ

Пәйгамбәрләрнең солтаны булган Әфәндебезнең мөхтәрәм атасы Габдулла хәзрәтләре 18 яшендә һәм анасы Әминә җәнабләре дә 14 яшендә булган вакытта, араларында никахлашу булды. Габдулла хәзрәтләре сәфәрдә булганда авырып Мәдинә шәһәрендә вафат булды. Ул 25 яшендә иде. Кабер шәрифләре Мәдинәдә урнашкан. Әфәндебез хәзрәтләре бу вакыт ике яки сигез айлык хәлендә калды.

Җәнаб Рәсүл Әфәндебез хәзрәтләре гарәпләр арасында “Гам фил” (Фил елы) дигән мәшһүр булган елда рабигыльәүвәл аеның 9 нчы дүшәмбе көнне таң вакытында Мәккә шәһәрендә дөньяга килеп “Мөхәммәд” дип исем кушылды (Милади белән 571 нче ел, Европа хисабы белән 20 нче апрель һәм Руми – Руси хисабы белән 17 нче апрельдә буладыр). Бәдәви гарәпләрдән Бану Сәгд кабиләсенең Харис бин Габделгүззә хатыны Хәлимә бинт Зөәйб сөтен имезеп һәм тәрбия итүе сәбәпле, ошбу бәдәви гарәпләрдә 2 яше тәмам булганына кадәр торды һәм соңыннан анасы Әминә җәнабләренә тапшырылды. Хәлимәдән алданрак Әбү Ләһәб җариясе булган Сөвәйбә бер кадәр вакыт үз сөтен имезеп торды. Атасы вафат булуы сәбәпле, бабасы Габдел-Мотталиб тарафыннан тәрбияләнде.

Габдел-Мотталиб, гарәп кавеме арасында бик күренекле һәм хөрмәтле зат булганга, Кәгъбә шәриф янында утырган вакытта, гарәп уллары моның хозурында әдәпле утырып, үзенең уллары да хөрмәт йөзеннән аякларына басып кул кушырып торыр иде. Фәкать бер ялгыз, сабый булган Әфәндебез хәзрәтләре барып утырыр, Габдел-Мотталиб та аны белеп кулы белән аркасыннан сыйпап сөяр: “Бу улым бөек бер адәм булса кирәк!” – дип сөйләр иде.

Әминә җәнабләре, Өмм Әйман белән бергә Әфәндебез хәзрәтләрен берлектә алып Мәдинә шәһәренә карендәшләрен һәм хәзрәт Габдулла каберен зиярәт итү нияте белән сәфәр кылды. Хәзрәти Әминә һәр ел, бер мәртәбә барып мөхтәрәм ирен зиярәт итеп килә иде. Ошбу сәфәрләреннән кайтып барганда Мәдинә шәһәреннән ерак түгел “Әбвә” исемле авылга җиткәндә Әминә җәнабләре хасталанып вафат булды һәм шушы җирдә җирләнде. Әфәндебез хәзрәтләре ошбу көннән игътибары ата белән анадан ятим булырак калды, яше 6-7 дә иде. Мәккәгә исә Өм Әйман кочагында кайтты.

Хәзрәт Габдулла, Әминәдән башка хатын алмады һәм Әминә дә икенче бер иргә кияүгә бармады, Әфәндебез хәзрәтләреннән башка балалары да булмады.

Галәмнең горурлыгы Әфәндебез хәзрәтләре 8 яшь вакытында Габдел-Мотталиб вафат булгач сөекле бабасыннан мәхрүм калганын белеп гәүдәсе янында елап торганы риваять ителә. Моннан соң әтисенә атасы һәм анасы ягыннан туган булган Әбү Талиб тәрбиясенә күчеп, аның йортында яшәде. Әбү Талиб пакь мәрхәмәтле һәм шәфкатьле бер зат булды, Әфәндебез хәзрәтләрен бик сөеп һәм балаларыннан артык рәвештә кайгыртып тәрбия итә торган иде.

### ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗНЕҢ ЯШҮСМЕРЛЕК ВАКЫТЫ

Рәсүл Әкрам хәзрәтләре 9 белән 12 яшьләре арасында булган вакытта Мәккә халкының сәүдә кәрваннары Шам сәфәренә чыгарга хәзерләнә иде. Әбү Талиб ошбу кәрван белән берлектә сәфәр кирәк-яракларын күрде. Фәкать тәрбиясендә булган Пәйгамбәребезне кызгану сәбәпле үзе белән бергә алып Шам сәфәренә чыкты. Шам мәмләкәтенә кереп Бусра шәһәре янында ял иткән вакытта, ерак түгел җирдә бер гыйбадәтханәдә гыйбадәт итеп торучы Бәхирә дип билгеле булган руханый (монах) боларның яннарына килде һәм: “Гарәп йортында бер пәйгамбәр чыгарга тиешле иде, бу турыда сездә хәбәр юкмы?” – дип сорады. Кәрван халкы да бу турыда бер нәрсә белмәгәннәрен сөйләде һәм хәрәкәт итеп юлларын дәвам итте.

Якынча 20 яшьләрендә вакытта бер тарафта корайш кабиләсе белән кинәнә кабиләсе һәм икенче тарафта кайс кабиләсе булган хәлдә бер сугыш булды. Үзенең якыннары булган Зөбәйр, Әбү Талиб, Хәмзә, Габбәс белән берлектә ошбу сугышта Әфәндебез хәзрәтләре дә булды, ошбу якыннарына ярдәм итеп, фәкать пәйгамбәрлек килгәннән соң бу турыда үкенеч белән сөйләгәне билгеле. Гарәп халкы арасында “Йәүмү фиҗар” дигән мәшһүр булган вакыйга ошбудыр.

Шушы сугыштан соң беркадәр вакыт узгач, гарәп уллары Габдулла бин Җүдгән йортына җыелып, алдагы гасырда золым һәм хыянәткә каршы ясалган “Хилф әл-Фөзул” исемле җәмгыятьне яңарттылар вә Мәккә шәһәрендә золым һәм җәберләкне бетерү хакында бер-берсенә сүз бирделәр. Әфәндебез хәзрәтләре, Габдел-Мотталиб уллары белән берлектә ошбу җәмгыятьтә була һәм моның хакында: “Яшь вакытымда абыйларым белән бергә Габдулла бин Җүдгән йортында булган “Хилф әл-Фөзул” җәмгыятендә булдым, шуннан гаять шат идем, әгәр дә шуның белән бер җәмгыять ясалса иде, бу көндә дә ул берлектә булыр идем!” – дип сөйләгән булган.

25 яшьләренә җиткәндә гарәп сәүдәгәрләренең мәшһүрләреннән булган Хәдичә бинт Хүвәйлид малы белән сәүдә өчен Шам сәфәренә чыкты һәм бу сәфәрдә Хәдичәнең Мәйсәрә исемле колы белән һәммә бергә бардылар. Сәфәрләре мөбарәк булып һәм өмет итүләреннән күбрәк файда күреп кайттылар.

Ошбу сәфәрдән калып бер-ике ай үткәннән соң “Аллаһ илчеләренең горурлыгы” Әфәндебез хәзрәтләре, Хәдичә (Аллаһ аңардан разый булсын) белән никахлаштылар. Бу вакыт Рәсүл Әкрам 25 яшьтә хәзрәти Хәдичә 40 яшьтә булыр иде.

Хәдичә кебек акыллы һәм игътибарлы бу хатын белән никахлашу сәбәпле Әфәндебез хәзрәтләре бөек бер дәүләткә лаеклы булды. Шуңа күрә һәрбер максаттан чара табу мөмкинлеге булып та, моннан файдаланмыйча һәм яше олылыгы нисбәтеннән, фикер диңгезендә тончыккан буларак йөрер һәм ялгызлыкны яратучы булыр.

35 яшьләренә җиткән вакытларында гарәп халыклары Кәгъбәне яңартырга карар боерды. Бу вакыт Кәгъбә адәм биеклегендә булган дүрт дивардан гыйбарәт булып, өсте ачык һәм күп җирләре бозылган иде. Гарәпләр Кәгъбәне нигезенә кадәр сүтте һәм яңадан диварларына биекләндереп өстенә уратты. Җиддә шәһәре янында ком өстендә утырып калган бер көймәнең такталарын һәм башка агачларын ташып, кирәк җирләренә куйдылар. Фәкать “Хәҗәр Әсвәдне” урынына куяр өчен һәр кабилә үзен хаклы күрде, араларыннан берсе дәгъва белдерде. Мәчет ишегеннән иң элек керүче адәмне хаким итеп куеп, ошбу дәгъваларына бүләргә карар боердылар. Шул вакыт көтмәгәндә мәчет ишегеннән “Галәмнәрнең горурлыгы” Әфәндебез хәзрәтләре килеп кергәч, һәрбере “Мөхәммәд әмин!” – дип шат булдылар һәм вакыйганы сөйләп бер тиешле чара булына өмет белдерделәр. Әфәндебез хәзрәтләре дә “Хәҗәр Әсвәдне” бер кием өстенә куйдырды, кабилә улларыннан киемнең кырыйларыннан тотыныл күтәртеп, урынына китерде. Бирелә бөек бер фетнә ошбу рәвештә тәмамланган булды.

### МӨХӘММӘД ГАЛӘЙҺИССӘЛӘМГӘ ПӘЙГАМБӘРЛЕК ИҢДЕРЕЛГӘН ВАКЫТ

40 яшендә Әфәндебез хәзрәтләренә Җәбраил фәрештә аркылы вәхи килә башлады. Иң элек яшерен сурәттә сурәттә буларак халыкларны иманга чакыра торган булды.

Ислам динен кабул иткән беренче хатыннардан хәзрәти Хәдичә, ирләрдән Әбү Бәкер әс-Сиддыйк, яшь улларыннан хәзрәти Гали , азат булган коллардан Зәйд бин Харис, азат булган җарияләрдән Өмм Әйман булган.

Алардан соң ислам динен кабул итте: Госман бин Гаффән, Зөбәйр бин әл-Гәввам, Габдерахман бин Гауф, Сәгд бин Әбү Ваккас, Талхә бин Габдулла, Сөһәйб әр-Руми, Габдулла бин Мәсгуд, Әбү Зәрр әл-Гыйфәри һәм башкалар.

Пәйгамбәрлек килгәннән соң 4 нче елда ачык сурәттә иманга чакыру башлану сәбәпле, мөшрикләр, Әфәндебез хәзрәтләренә һәм аның сәхабәләренә җәфа кылырга керештә, кимсетеп һәм мәсхәрәләп һәр затны күрсәттеләр.

Мәккә халкыннан гомуми рәвештә моның белән җәфа күргәннәре артып киткәннән соң Әфәндебез хәзрәтләренең билге бирүе һәм яраклы күрүенә нигезләнеп сәхабәләр Хәбәш йортына һиҗрә кылырга карар боерды һәм иң беренче булып берьюлы 12 ир вә 4 хатын гыйбарәт бер Таифә гизле сурәттә күбесе дә җыен буларак Мәккәдән чыгып китте; Кызыл диңгезне кичеп Хәбәш падишаһы Нәҗәш хозурына барып сыгындылар. Хәзрәти Госман белән хатыны Рөкаййа бинт Рәсүлуллаһ, Әбү Сәләмә белән хатыны Өмм Сәләмә, Габдулла бин Мәсгуд, Зөбәйр бин әл-Гаввәм, Габдерахман бин Гауф шулар арасында булды. Алар якынча өч ай вакыт Хәбәш җирендә торганнан соң корайш гарәпләре Рәсүлуллаһ һәм сәхабәсенә зыян боерганны туктатты дип ялган бер хәбәр ишеткәч асыл ватаннары булган Мәккә шәһәренә Әфәндебез хозурына кабат кайттылар. Фәкать мөшрикләргә ачулары, зыяннары алдагыдан күп мәртәбә артуын ачык рәвештә Мәккә янына җиткәндә ишетеп бик өметсез булдылар.

Вакыйга Мәккә мөшрикләре Рәсүл Әкрам җәнабләренә һәм мөхтәрәм сәхабәләренә җәфаларын озайтудан түгел, бәлки көннән-көн арттырырлар, бер-береннән уздырырлар иде. Әфәндебез хәзрәтләренә шушы эштән катгый рәвештә туктамаган бөек бер кабахәт гамәл итеп бөтен һашим нәселеннән кискен бойкот игълан иттеләр һәм һич аңлаешлы итеп алар белән мөнәсәбәт кормаячакларын бер хаҗәт-кагыйдә язып, Кәгъбә эченә элделәр. Әбү Ләһәб һәм гаиләсе мөшрикләр тарафында калып, аннан башка булган Бану һашим мөселман һәм кяферләр “Шигъб Әбү Талиб” исемле җирдә өч ел микъдар вакытта чолгап алынган килеш тордылар.

Шушы вакыт Мәккәдә көн күрү ихтималы калмаганны белеп Әсхаби Кирам (Пәйгамбәребезнең сәхабәләре) икенче тапкыр Хәбәш йортына һиҗрә кылырга мәҗбүр булды. Бу юлы һиҗрә кылдылар 83 ир һәм 18 хатын булып, Җәгъфәр бин Әбү Талиб белән хатыны Әсма бинт Гумәйс, Габидулла бин Җәхш белән хатыны Өмм Хәбибә бинт Әби Суфьян алар белән бергә иде.

“Шигъб Әбү Талиб” җирлегендә Бану һашимнең күрелгән мәшәкатьләре, чыккан кыенлыклары аңлатырлык дәрәҗәдән кичкән иде. Яннарына читтән кеше керү өчен дә чыгып йөрү һәм дуслык тоту тыелуы сәбәпле, гадәттә бер төрмәдәге кебек булдылар ки, табылган болын һәм агач яфракларын җәннәт нигъмәтләре урынына күреп ашадылар.

Соңыннан кайбер гарәп уллары бу хәлгә риза булмаганнарын бәян иттеләр, фетнә чыгарулары сәбәпле, кискен рәвештә күтәрелде һәм "Шигъбтә" боларның бер өлеше ирекле булды.

Пәйгамбәрлек иңгәннән соң, 10 нчы елны һәм һиҗри белән 3 нче елда, Әбү Талиб вафат булды. Моннан 3 көн соңрак мөэминнәрнең анасы Хәдичә (Аллаһ аңардан разый булсын) хәзрәтләре дә дөньядан китте. Ошбу җәһәттән Әфәндебез хәзрәтләре карарсыз кайгырды, ошбу ел да "Гам әл-Хөзен" (кайгы елы) дип аталган; үзенең ватанында һәм үзенең туганнары вә якын кешеләре арасында булган хәлдә, аерылып читтә яшәүче буларак калды. Шуның өчен Әбү Талиб югары дәрәҗәдә шәфкатьле һәм мәрхәмәтле булганга күрә, аннан килүенә кадәр Әфәндебезне яклар һәм аның өчен үз өстенә күп мәшәкатьләр йөкләр иде. Хәзрәти Хәдичә дә, бөтен халык ялган дип әйткәндә, беркайчан да Әфәндебез хәзрәтләренә шик белдермәде һәм бөтен халык мыскыллаган һәм хәрәкәт иткән вакытта да, даими юатты һәм бу гамәлне яратмыйча торды. Шул сәбәпле, аларның вафаты белән Әфәндебез хәзрәтләре иң якын яклаучыларны, ачык һәм ярдәм итүчеләрне югалтты. Алар вафат булгач, мөшрикләр тагын да олы бер форсат табып Әфәндебезгә алдагыдан күбрәк җәфа китерде һәм кимсетте, сихерче һәм каһин диделәр, мәҗнүн һәм шагыйрь дип сөйләделәр. Юлларда каравыл торып һәм әйтелеп үткән барлык җәмгыятьләрдә йөреп халыкларны, ерак җирләрдән килгән мөсафирларны нәфрәт тудырыр өчен һәр төрле ялганнар уйлап чыгарып сөйләп йөрделәр. Хосусый үзенең күршеләре һәм якын карендәшләре булган Әбү Ләһәб белән хатыны Өмм Җәмилә бинт Хәрб һәм Гөкбә бин Әбү Мөгайт һич рәхәтлек күрсәтмәде; намаз укырга керешкән булса, өстенә нәҗесләр күтәреп салды, аш-суына пычрак нәрсәләр ташлады, юл өстенә тигәнәкләр һәм чәнечкеле чыбыклар салып куя иделәр. Өч айга кадәр бу хәлне сабыр итеп торды да, соңыннан аптырап һиҗрә кылу нияте белән Таифә шәһәренә китте, фәкать өметен баглап файда монда һич булмады: Таифә халкында хәер күрмәде.

Таифә халыклары Әфәндебезнең сүзенә колак салмады, уларының котыртуларына күрә коллары һәм балалары ташлар белән атты, мөбарәк баш һәм аякларын канатты. Ошбу вакытта янында булган Зәйд бин Харис Әфәндебезне сакларга тырышлык күрсәтте һәм үз гәүдәсе белән калкан булыр иде. "Ахыргы әмер" (ахыргы пәйгамбәр) Әфәндебез хәзрәтләре кабат Мәккәгә кайтырга мәҗбүр булды һәм кайткан вакытында юлда: "Әй минем Раббым! Мин зәгыйфь, монда халык арасында хөрмәтем калмады! Әй зәгыйфьләргә ярдәм һәм юраучы Аллаһ! Ачуыңа очраудан мине саклар булсаң, дөньяның һәрбер кыенлыгына түзәргә бурычымдыр!" – дип мөнәҗәт итте һәм Мәккәгә килгәндә Мутгәм бин Гади сак астында буларак шәһәргә керде.

Бөтен гарәп халкы ярдәме белән каршы торганнары һәм көннән-көн усаллыкларын һәм каршылыкларын арттырып һәртөрле кыенлыклар һәм җәфалар күргән Әфәндебез хәзрәтләре боларның иманга килүләренә өметен өзеп һәм ошбу сәбәптән, башка гарәп кабиләләренә дәгъвәт итәргә кереште. Гарәпләргә билгеле һәм мәшһүр изге җирләрендә йөреп үзенә максат итте, ерак җирләрдән Мәккәгә хаҗ кылыр өчен килгән адәмнәргә ислам динен бәян итеп дәгъвәтләр иде.

Пәйгамбәрлекнең 12 нче елында Мәдинә шәһәреннән хаҗ кылып килгән гарәпләргә ислам динен аңлаткан вакытта бер төркем гарәпләр Мәккәдә "Гакәбә" исемле урында Әфәндебез хәзрәтләрен кабул итте һәм икенче ел тагын да күбрәк килеп Рәсүлуллаһ каршында бәйгать биреп ислам динен кабул итеп кайтып киттеләр.

Шул исәптән Мәдинә шәһәрендә ислам дине тамыр җәя башлаганны күргәннән соң төрле зәхмәтләр чыгып тора торган булган сәхабәләр берәрберәр Мәккә шәһәреннән Мәдинәгә күчә башлады; диннәрен саклар өчен һәм рәхәтлек каршында гыйбадәтләренә зыян китермәү өмете белән карендәш кабиләләренә, ватан асылларын ташлап аерылып китеп мәшәкатьләренә йөкле булдылар. Хәтта бер вакыт Мәккәдә Әфәндебез хәзрәтләре белән Әбү Бәкер әс-Сиддыйк, Гали әл-Мөртәда һәм Сөһаиб, Зәйд бин Харисә һәммә дә кайбер зәгыйфь хәлсез мескеннәр генә калды.

Әфәндебез хәзрәтләре янына барып Әбү Бәкер әс-Сиддыйк хәзрәтләре Мәдинәгә һиҗрә кылу хакында рөхсәт сорады. Рәсүл Әкрам: "Сабыр ит! һиҗрә хакында җәфа булачакны мин һәммә өмет итмим, әгәр дә җәфа булса берлектә сәфәр итәрбез", – диде. Моңа кушылып Әбү Бәкер әс-Сиддыйк хәзрәтләре, Әфәндебез белән берлектә сәфәр итәчәк сурәттә сәфәр яракларын күрә башлады.

Мәдинә халкы бәйгать биреп киткәннәрен ишеткәч, мөшрикләр өсләренә күк йомрылып төшкән рәвештә кайгы-хәсрәткә төштеләр; гадәттән тыш ачулары килде һәм форсат үтмәгәнне бу турыда җитди бер киңәшләшү өчен, киңәш йөртә торган "Дәрүл Нәдвәгә" җыелдылар. Мөшрикләргә иң бөекләреннән һәм иң акыллыларыннан гыйбарәт булган ошбу җәмгыять тарафыннан һәрбер кабиләнең каһарман егетләре Әфәндебезнең өе янына караңгыда җыелып һәм ярдәм белән һөҗүм итәргә булдылар һәм шул вакыт низамыны күрә, соңыннан һашим кабиләсе файдасына дийәт (кан хакы) түләргә карар боерылды.

### ҺИҖРӘТ ЧОРЫ

Зикер ителгән карар кабул ителгәнчә, Мәккәдә булган гарәп кабиләләренең егет һәм баһадирлары кич белән җыелып Әфәндебез хәзрәтләренең йортын чолгап алды.

Шуның өчен ошбу кичәдә Рәсүл Әкрам хәзрәтләре өеннән чыгып, "Үә җәгалнә мин бәйнә әйдиһим сәддән вә мин халфиһим сәддән фәәгшәйнәһүм фәһүм лә юбсыйрун" аятен укып чыгып китте. Чолгап алучылар бергәләшеп тирән йокыда булыр иделәр. Бераз барганнан соң, Әбү Бәкер әс-Сиддыйк белән очрашып берлектә шәһәрдән чыгып киттеләр.



Дошманнары артларыннан чыгып, Мәккәгә кире кайтмасыннар яки ни булса да берәр мөнәсәбәтсез эш булмасын ниятенә нигезләнеп, шәһәрдән бик ерак түгел "Сәүр" тавында булган куышлык эченә кереп яшеренделәр һәм бу урында өч кич тордылар.

Хәзрәти Әбү Бәкернең улы Габдулла, һәр кичәдә яннарына барып куна һәм сәхәрдән торып шәһәргә кайтып китә иде, ошбу сәбәптән Мәккә халкы моның тау куышлыгында кунганын белмәсләр иде. Шәһәрдә булган мәҗараләрне, хәбәрләрне ишетеп, кич җиту белән куышлыкка бара иде. Һәм һәр көн иртә белән Әбү Бәкер әс-Сиддыйк колы Гамир бин Фөһәйр куй көтүен куышлык тарафына алып барып таптатып, Габдулла аяк эзләрен югалтыр иде.

Гарәпләрнең каннары бераз сыенгач һәм эзләүдән дә тукталганнан соң тауның куышлыгыннан чыктылар һәм Мәдинә юлына төшеп сәфәр кылдылар. Әбү Бәкер әс-Сиддыйк хәзрәтләренең колы Гамир бин Фөһәйр, юл башчысы итеп ялланды, Габдулла бин Өрәйкыйт исемле бер мөшрик гарәптә алар белән берлектә булды.

Боерыкларын тиешле кемнәргә тапшырыр һәм кулында булган әманәтләрен сәхабәләренә кайтарыр өчен дә Әфәндебез хәзрәтләре, хәзрәти Галине (Аллаһ аңардан разый булсын) үзенең йортында Мәккәдә калдырды.

Пәйгамбәрлек килгәннән соң, Әфәндебез хәзрәтләренең Мәккәдә кичергән гомере һиҗри вакытыннан 13 ел булып, ә яше 53 тә иде.

Милади белән 622 нче ел рабигыльәүвәл аеның 8 нче дүшәмбе көнендә юл өстендә һәм Мәдинәгә дә берничә чакрым ераклыкта булган Кобә авылына сау-сәламәт буларак килеп керделәр. Кобәдә дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе көннәр торып, 12 нче рабигыльәүвәл җомга көн Мәдинәгә юнәлделәр һәм бик камил бер хөтбә укырга җомга намазын укыдылар .

Әфәндебез "Аллаһ илчеләренең горурлыгы" хәзрәтләренең һиҗрәләре иң бөек хәдисәләрдәндер. Моның сәбәбе ислам әһелләре мөшрикләрнең җәберләвен һәм кыерсытуларын тәмам, хөррият каршында гыйбадәтләрен вакытында кылырга һәм ислам өндәвен җиренә китерергә килештеләр. Ислам дине шәһрәт тапты, гарәп кабиләләре төркем-төркем буларак килеп бәйгать бирде, дөньяның иң ерак һәм иң кыргый якларына кадәр иман таралып "Хәййә галәл фәләх!" чакыруына тәхетләр тетрәнде. Ошбу сәбәптән алда искә алынган вакыйга әһел ислам каршында тарих башы буларак кулланылыр һәм кулланылырга тиешледер дә .

Рәсүлуллаһ Әфәндебез хәзрәтләренең Мәккәдән чыгуы һәм Мәдинәгә юл тотуы, ничектер, Мәдинә шәһәренә ирешә. Ошбу хәбәр билгеле булуы белән Мәдинә халкына хасыйл булган шатлыкны һич сорамагыз! Моны исә алар үзләре дә аңлатып бетерә алмаслар.

**Ризаэддин ФӘХРЕДДИНнең**
**"Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм" китабыннан.**
**"Хозур" нәшрият йорты**

**(дәвамы киләсе санда)**

Мәкалә "Казан Гипронииавиапром" акционерлык җәмгыяте булышлыгында басыла.
420127, КАЗАН ШӘҺ., ДЕМЕНТЬЕВ УР., 1
т.: (843) 571-95-48

# “Исламның асылын гыйлем аша гына җиткереп була

**Республика районнарыннан 300 гә якын башлангыч дини белем бирүче мөгаллим “Казан” милли-мәдәни үзәгенә “Мәчет каршындагы курсларда дини фәннәрне укыту” темасына багышланган квалификация күтәрү курсларына җыелды.**

Чара КИУның дини фәннәр кафедрасы мөдире, Казан шәһәре казые Габдулла хәзрәт Әдһәмовның аһәңле итеп Коръән укуы белән ачылды һәм мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның сәламләве белән дәвам итте. “Ислам асылын гыйлем аша гына түгел, дөрес итеп җиткереп була. Барчабыз да яхшы аңлый, сыйфатлы дини белем мәхәлләне тәрбияли, үстерә, ныгыта. Шуңа күрә дә дини мәгариф системасы – Диния нәзарәтенең зур игътибар иткән өлкәсе. Соңгы дистә еллар дәвамында, бернинди авырлыкларга карамастан, республикада бөрбөтен дини мәгариф системасы булдырылды. Дини мәгариф башлангыч белем бирүдән башлап вузга кадәр дәвам итә. Быел исә дәүләт җитәкчеләре ярдәмендә Болгар ислам академиясен булдыру турында карар кабул иттек. Моны – дини мәгарифнең иң югары баскычы дип әйтә алабыз. Аллаһы боерса, ислам галимнәрен үзебездә – Татарстанда үстереп булачак”, - диде мөфти хәзрәтләре.

Форсаттан файдаланып, Камил хәзрәт дини остазларга үзенең рәхмәтләрен дә ирештерде һәм саваплы эшләрендә Аллаһы Тәгаләнең рәхим-шәфкатьләрен, бәрәкәтләрен теләде.

Мөфти хәзрәтләре мөгаллимнәргә бүгенге дини вәгазьнять турында да аңлатты һәм гыйлемсез кешеләргә ияручеләрдән булмаска чакырды.

ТР мөфтие урынбасары, Россия ислам институты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин сүзләренчә, дини белем бирү юнәлешендә мәгариф системасы бер тәртипкә салына. Ул шулай ук мәдрәсәләрдә 3 меңләп кеше укыса, мәчетләр каршында эшләгән курсларда республикада 30 меңләп кеше белем алуын ассызыклады. “Бу — 10 тапкыр күбрәк һәм әлеге курсларда укучыларның шактые намаз укый башлый. Дин нигезләрен сездән ничек кабул итсә, аларның язмышлары да алга таба шул рәвешле хәл ителергә мөмкин. Мәчетләр каршындагы курслар безнең барыбыз өчен дә иң мөһим факторларның берсе”, - диде ул.

Рәфыйк Мөхәммәтшин, ТР мөфтие сүзләрен хуплап, дини яктан белемсезлекнең аяныч хәлләргә китерүен ассызыклады. “Ышанып, мин мөселман дәүләте төзим, дип Сүриягә китүчеләр шактый. Аларда дөрес мәгълүмат булмау, мәгълүматны ялгыш кабул итү мәгариф системасын киңрәк җәелдерү, ислам дине хакында дөрес мәгълүматны халыкка җиткерү бурычы куя, - диде.

ТР Президенты Аппаратының эчке сәясәт департаменты хезмәткәре Айнур Солтанов бу җыенның кирәклеген ассызыклады. “Мәчет каршындагы курслар - кешеләр массакүләм рәвештә белем ала торган, иң күп укытучылар җәлеп ителгән өлкә. Диния нәзарәте уку-укыту әсбаплары әзерли, әлеге курсларны методология белән тәэмин итә. Әмма бу өлкәдә кыенлыклар җитәрлек, - диде ул һәм чишеләсе мәсьәләләр рәтенә ислам турында дини белемнең аз булуын, мәчет каршындагы укуларда белем бирүче укытучыларның белем дәрәҗәсен күтәрергә кирәклекне атады. – Яшьләр әлеге курсларга йөри, аларда дингә карата хөрмәт һәм мәхәббәт тәрбияләнә. Әмма аларга тулаем белем бирелми, ислам хакында дөреслек ачылып бетми. Шуңа да яшьләр интернеттан эзләнергә мәҗбүр. Бу исә аяныч нәтиҗәләргә китерергә мөмкин”, - дигән фикердә А. Солтанов.

Мөгаллимнәрнең укуы исламдагы фирка һәм төркемнәр, гакыйдә, фикыһ, сира, тәҗвид фәннәрен укыту мәсьәләләренә бәйле лекцияләрне тыңлау белән дәвам итте. Чакырылган лекторлар арасында “Мөхәммәдия” мәдрәсәсе мөгаллимнәре Камил Вәлиуллин, Рамил Зарипов, КИУның дини фәннәр кафедрасы мөдире, Казан шәһәре казые Габдулла хәзрәт Әдһәмов, “Мөхәммәдия” мәдрәсәсе директоры урынбасары Зөлфәт Габдуллин, Кукмара мәдрәсәсе директоры Ришат Курамшин, ТР МДНнең фән һәм уку-укыту бүлеге җитәкчесе Айдар Карибуллин, ТР МДНнең яшьләр белән эшләү бүлеге җитәкчесе Айгөл Биктимерова бар иде.

DUMRT.RU

## Мөфти Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИННЫҢ мәчет каршындагы курслар мөгаллимнәре белән очрашуда ясаган чыгышы



**Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим! Мөхтәрәм имамнар, мөгаллимнәр, кунаклар! Әссәләәмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкатүһ!**

Барча мактауларыбыз Аллаһы Тәгаләгә булсын! Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу гәләйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә һәм барлык сәхабәләренә Аллаһының рәхмәте һәм сәламе булсын!

Сүзне меңләгән кешеләргә дин нигезләрен өйрәткән мөгаллимнәргә рәхмәт сүзеннән башлыйсы килә. Сезгә Аллаһы Тәгаләнең рәхим- шәфкатьләре, бәрәкәтләре язсын. Ике дөнья рәхәтен күрергә насыйп итсен!

Мөхтәрәм җәмәгать! Ислам асылын гыйлем аша гына түгел, дөрес итеп җиткереп була. Барчабыз да яхшы аңлый, сыйфатлы дини белем мәхәлләне тәрбияли, үстерә, ныгыта. Шуңа күрә дә дини мәгариф системасы – Диния нәзарәтенең иң зур игътибар иткән өлкәсе.

Соңгы дистә еллар дәвамында, бернинди авырлыкларга карамастан, республикада бөрбөтен дини мәгариф системасы булдырылды. Дини мәгариф башлангыч белем бирүдән башлап, вузга кадәр дәвам итә. Быел исә дәүләт җитәкчеләре ярдәмендә Болгар ислам академиясен булдыру турында карар кабул иттек. Моны дини мәгарифнең иң югары баскычы дип әйтә алабыз. Аллаһы боерса, ислам галимнәрен үзебездә – Татарстанда үстереп булачак.

Бүгенге көндә мөселманнар өчен мөмкинлекләр күп. Әмма исламнан ерак кешеләр өммәтебездә төрле проблемалар барлыкка китерә. Мәсәлән, интернетта берничә атна элек видео тараттылар. Күбегез күргәнсездер, анда берәү фетнәгә өнди. Милләтара, динара көрәшкә чакыра. Дәүләткә каршы барырга куша. Мәчетләрне җимергән, мөселманнарны үтерүче җинаятьче кешеләр Ислам дәүләте түгел, “Иблис дәүләте” төзеп, тарихи вакыйгалар белән уйнамакчы булалар. Тарихта булып үткән кайбер хәлләрне үзләренчә шәрехләп, фикерләрне бутыйлар. Ватанпәрвәрлек, үз халкыңны ярату, туган җиреңне кадерләү кебек ихлас хисләрне начарлыкка бормакчы булалар. Ләкин бу хисләр берничек тә башка дин, милләт кешеләренә карата җинаять кылуга әйләнергә тиеш түгел. Чөнки Раббыбызның рәхмәте киң, барчабызга да җитә.

Шуны аңласак иде, кансыз һәм надан кешеләрнең гамәлләре аркасында бөтен исламны түбәнсетү күзәтелә.

Нүәйм ибн Хаммадның “Әл-Фитан” китабында Гали ибне Әбү Талибтан (аңар Аллаһының рәхмәте булсын) килгән хәдис язылган. Ул хәдистә болай диелгән: “Кара әләмнәр (флаглар) күрсәгез, җиргә иелегез һәм кымшанмагыз. Зәгыйфь кешеләр килер, аларга берәү дә әһәмият бирмәс. Аларның йөрәкләре тимер төсле каты булыр. Һәм аларның үзләре уйлап тапкан дәүләтләре булыр. Вәгъдәләрендә тормаслар, килешүләрне үтәмәсләр. Алар үзләрен хаклы дип әйтерләр, әмма дөреслектән ерак торырлар. Бер-берсенә шәһәр атамаларын кушамат итеп тагарлар. Чәчләре хатынкызларныкы төсле озын булыр. Аннары берберсе белән талаша башларлар. Менә шул чакта Аллаһы кемнәргә тели – шуларга хакыйкатьне юллар”.

Җәмәгать! Берләшкән җинаятьчеләрнең дине юк. Андыйларның дине була да алмый. Алар кешеләрне исламнан ераклаштыралар, динебезгә карата тискәре карашлар уяталар. Чөнки хаксыз һәм гаделсез рәвештә кеше үтерүне “җиһад кылу” дип атыйлар. Безгә юл күрсәтүче китабыбыз Коръәни Кәримдә моны раслаучы бер аңлатма да юк. “Җиһад” сүзе ул – ислам дине, Аллаһы Тәгалә юлында булу һәм гыйбадәт кылу өчен тырышу. Ул һич тә үзүзенә кул салуга да, башка кешеләрнең канын коюга да өндәми. Мөселманнарга каршы фетнә чыгару, дошманлык хисе уяту, изге рәҗәб, шәгъбан, рамазан айларында кан кою – болар берсе дә җиһад түгел, ә җинаять. Ислам бер кешене үтерүне бөтен халыкны үтерүгә тиңли.

Җинаятьчеләрнең телләре гел тәкбир әйтеп торса да, маңгайлары гел сәҗдәдә булса да алданмагыз. Үтерү нияте кергән җинаятьчеләр белән диннең бернинди бәйләнеше юк һәм була алмый. Бернинди гаебе булмаган кешеләрне санаулы көннәрдә юкка чыгаралар. Бу исламнан түгел! Бу Аллаһы Тәгалә кушкан юл түгел! Җинаятьчеләрне аклап һәм аларны нинди дә булса дин әһелләре сафына кертү турында сүз дә куерта алмыйбыз.

Бохари һәм Мөслимнең хәдис җыентыкларында болай язылган: “Ахырзаманда акылсыз яшьләрдән торган төркем барлыкка килер. Алар Пәйгамбәребез саллаллаһу гәләйһи вә сәлләм сүзләрен сөйләрләр, Коръән укырлар. Әмма сүзләре тамак төбеннән узмас һәм үзләре исламнан җәядән атылган ук төсле очып чыгарлар. Юлыгызда очрасалар, алар юкка чыкканчы көрәшегез. Аларга каршы көрәшүчеләргә Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә әҗерен бирер”.

Мөхтәрәм җәмәгать! Балаларыбызга, яшьләребезгә хуҗа булып, дин һәм иман мәсьәләләрен дөрес итеп өйрәтик. Тикшермичә, аңламыйча теләсә нинди белемне кабул итмик. Сүземне исә дога белән тәмамларга телим: “Әй, Раббым! Белемебезне, аңыбызны арттырып, безне салих колларыңнан әйлә!”.

# СӨНГАТУЛЛА БИКБУЛАТ

**Соңгы елларда Татарстан галимнәренең тикшеренүләрендә татар тарихында зур урын алып торучы шәхесләрнең тормышы, тәҗрибәсе һәм фәнни белемнәре еш чагыла. Бу җәһәттән аеруча мөһим булып XIX гасырның икенче яртысы – һәм XX гасырның беренче яртысы тора. Әлеге чорның тарихи шәхесләрен тикшергәндә С. Бикбулатовның шәхесе аеруча зур кызыксыну тудыра. Бер яктан, ул – укытучы, язучы, галим, ислам белеме һәм гарәп теле галимнәре һәм шәкертләрендә соклану уяткан кеше, шул ук вакытта революциядән соңгы хакимиятнең кысрыклавына дучар була.**

Авыр тормыш юлына карамастан, ул һәрвакыт кеше булып калырга тырыша. Аның фикерләре революциягә кадәрге һәм бүгенге Россиядә тарихи китапларның һәм гарәп теле дәреслекләренең формалашуына ярдәм итә. Революциягә кадәрле чорда С.Бикбулатовның 16 эше дөнья күрә. Алар арасында, бүгенге вакытта киңәкле ислам тарихы һәм татар телендәге гарәп теле дәреслекләре бар. Ул вакытта туган тел буенча күләмле эшләр булмау сәбәпле, укыту гарәп китаплары буенча алып барыла. Бүгенге вакытта да аның китапларына мохтаҗлык кимеми. Россия ислам институты 2005 елда «Мабдауль-кыраат» китабының өч өлештән торган җыелмасын бастырып чыгара һәм башка нәшриятларда аның «Мабдау-нахү», «Мабдау-сарф» кебек хезмәтләре чыгарыла. Шулай да аңа иң зур танылуны 1999 елда кабаттан басылып чыккан «Хәзрәти Мөхәммәд» китабы китерә.

С.Бикбулатовның тормыш юлын 4 мөһим өлешкә бүлеп карарга мөмкин. Бу аның биографиясендәге үзгәрешләргә бәйле. Шул ук вакытта кайчак мөстәкыйль рәвештә, ә кайчак замана вакыйгалары, репрессияләр басымы астында Сөнгатулла Бикбулатовка карашларын, тормыш рәвешен, кызыксынуларын үзгәртергә туры килә.

### Беренче чор (27 ноябрь 1886 ел – 1891 ел)

Сөнгатулла Бикбулатов 1886 елның 27 нче ноябрендә Уфа губернасында, Эстәрлетамак шәһәренә якын булган Балыклы Күл авылында фәкыйрь крестьян гаиләсендә туа. Үз җирләре булмаганлыктан алар, камыт тегү белән шөгыльләнеп, вакытлы эшкә ялланып көн күргән. С.Бикбулатовның гаиләсе авырлыкларга түзә алмыйча, яхшы тормыш эзләп, Оренбургка юнәлә. Алар белән әтисенең ике энекәше дә күченә. Күчеп китеп 4 ай үткәч, Бикбулатовлар гаиләсенә көтелмәгән кайгы килә. 1891 елда гаилә башлыгы Нигъмәтулла Бикбулатов дөнья куя. Тол хатын кулындагы бәләкәй бала белән авыр хәлдә кала, авылга кайтудан башка чара калмый. Ул вакытта гаилә башлыксыз калса, бу зур фаҗигага әйләнә. Гомер итү өчен әнисе яңадан кияүгә чыгарга мәҗбүр була. Яңа гаиләдә кечкенә Сөнгатулла артык кашыкка әйләнә.

### Икенче чор (1891 – 1917 еллар)

Сөнгатулланы Оренбургка абыйлары янына җибәрәләр. Ләкин абыйларының үз гаиләләре һәм үз мәшәкатьләре. Артык кашыкны туйдыру авыр булганга, абыйлары Сөнгатулланы 9 яше тулгач 1895 елда күренекле «Хөсәения» мәдрәсәсенә урнаштыралар. Аның мәдрәсәгә әләгүе гәҗәп түгел: «Хөсәения» мәдрәсәсенә нигез салучылар – Хөсәеновлар Оренбургта ислам кануннары буенча ятимнәргә хәлдән килгәнчә ярдәм күрсәткән.

С.Бикбулатов бөтен тырышлыгын укуга бирә һәм бу нәтиҗәләрен дә күрсәтә. 1906 елда С.Бикбулатов «Хөсәения» мәдрәсәсен яхшы билгеләргә тәмамлый.

Чит илгә чыгып уку мөмкинлеге булмаган бик тырыш укучыларга «Хөсәения» мәдрәсәсе үз казнасыннан ярдәм күрсәтеп чит илгә җибәрә торган булган. Ислам тарихын һәм гарәп телен өйрәнү өчен «Әл-Әзһәр» университетында гарәп теле һәм әдәбиятын өйрәнүдән башка ул Каһирә педагогика институтында да укыган. 1910 елны педагогика институтын тәмамлап, ислам тарихы һәм гарәп теле белгечлеге алып, «Хөсәения» мәдрәсәсенә кайтып эшкә урнаша. Монда инде аның беренче китаплары чыга башлый.

... Китап язган кеше, әгәр дә ул нигез итеп икенчел хезмәт ала икән, аны галим итеп санап булмый. Бикбулатов нигез итеп таяну фикерләрен Коръәннән, Сахих Мөслим, Бохари, Уссудуль Габа, Ибн Кассир кебек авторлардан алган. Икенчел хезмәтләргә «Изгеләр бакчасы», Ән-Нәвавинең 40 хәдисен, Р. Фәхреддиннең «Җәвамигуль Кәлим» китабын кертергә була. Бу хезмәтләр төп чыганакларга таянып башкарылган. Бикбулатов хәдисләрне бик яхшы белгән. Ул хәдисләр терминологиясендә белгеч, төрле фәннәрдә киң гыйлемле булган.

Мәдрәсәдә Бикбулатов 1917 елга хәтле эшли. Һәм аның барлык хезмәтләре шул вакытларда язылган. Ләкин 1917 елда «Хөсәения» мәдрәсәсе «Дарульмөгаллим» татар институты булып үзгәртелә. Барлык укыту планнарында нигездә мәдәни белем бирү ягы гына карала.

### 1917 – 1948 еллар (өченче чор)

Инкыйлабның башлангыч чоры һәм бөтен илнең тормыш нигезләре үзгәрүе. Бу чор С.Бикбулатовның бөтен казанышлары, тормышка карашлары үзгәргән вакыт. С.Бикбулатовны ихтирам йөзеннән ислам белгече итеп кабул итәләр.

1917 нче елда ул «Милли автономия» һәм 422 «Милли мәҗлес» барлыкка китерүче комиссия составына сайланып куела.

1921 елда борынгы Шәрекъ культурасын өйрәнә торган Төркестан экспедициясендә катнаша һәм 15 кеше исәбендә Бохара шәһәренә бара.

1922 елда Диния нәзарәте әгъзасына кандидат итеп сайлана.

1927 елда «82 кеше хатына» кул куя. Бу эш партия һәм хөкүмәтнең татар әлифбасын латинчага (яңалиф) күчерү турындагы башлангычка каршы тору гамәле дип бәяләнә. С.Бикбулатовка каршы басым ясаулар башлана.

1917 елның 1 сентябреннән 1924 елның 30 маена хәтле ул Оренбургтагы Татар халык белем бирү институтында мәдәният тарихы укытучысы.

1924 елның 1 сентябреннән 1926 елның 30 маена кадәр Бохара мәгърифәт институтында үзбәк халык тарихы һәм география укытучысы.

1926 елның 1 сентябреннән 1929 елның 30 маена кадәр Казан шәһәрендәге Татар мәгарифе укытучылар техникумында география укытучысы.

1929 елның 1 сентябреннән 1932 елның 30 маена кадәр совет төзелеше техникумында география укытучысы.

1932 елның 1 сентябреннән 1937 елның 30 маена кадәр КДПУдагы эшчеләр факультетында география укытучысы.

1937 елның 1 сентябреннән 1941 елның 30 маена кадәр Казан шәһәренең махсус төзелеш мәктәбендә география укытучысы.

1941 елның 1 сентябреннән 1945 елның 10 декабренә кадәр Юдино районының Зур Яки милли урта мәктәбендә директор һәм география укытучысы.

1945 елның 15 июленнән 1948 елның 10 гыйнварына кадәр Казан дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияте кафедрасында өлкән укытучы.

С.Бикбулатов һәр эшкә тырышлык белән тотына. Кайбер шәкертләренең искә алулары буенча, ул тыныч, аек акыллы, бервакытта да тавыш күтәрми торган кеше, уку әсбаблары җитмәүгә карамастан, укыту эшен үз кулына ала һәм яңа уку китаплары чыгарырга тырыша. Ул бу эшен башкарып чыгарырга җитешә алмый, аны 1948 елның 10 гыйнварында, укытучылык тәртипләрен үтәмәвен сәбәп итеп, югары уку йортыннан куалар.

«82 кеше хатын»нан баш тартуы турында Т.Зарубина исеменә мөрәҗәгать хаты яза: «Кыскача әйткәндә, мин университетның югары уку йортында укыту таләпләрен үтәмәвем турындагы аңлатмасына каршы. Мин гарәп телен тирәнтен беләм, моны минем гарәп-фарсы сүзлегенә ясаган рецензиям раслый ала. Шулай ук моны бу сүзлек өстендә бергә эшләгән институт хезмәткәрләре дә дәлилли ала. Университетның кешене эшеннән, кыш көне, уку елы уртасында урамга куып чыгарган кыланышы совет тәртипләренә туры килми дип саныйм. Мин эштән бернинди алдан кисәтүсез азат ителдем. Бер сүз белән әйткәндә гаиләм иң сәламәт гаиләләрдән санала һәм бу минем идеологик яктан ышанычлы булуымны күрсәтә. Югарыда әйтеп үтелгәннәрдән чыгып, миңа мөнәсәбәттә килеп чыккан хәлне чишүгезне сорыйм».

### 1948 ел – 20 ноябрь 1954 ел (дүртенче чор)

Бу тулысынча онытылу, кулга алынуларны, гаиләнең репрессияләнүен көтү чоры. Колачы буенча тиңе булмаган репрессияләр дәвамында күренекле мөселман шәхесләр кимсетелә. Нинди дә булса эшләр өчен түгел, советка каршы сүзләр өчен җәза бирелә. Еш кына миллләттәшләребез татар булулары өчен җәзага тартыла. Нәтиҗәдә ярты ел эчендә 7675 кеше кулга алына, аларның 1550е суд органнары аша үткәрелә, ә 245е югары җәзага хөкем ителә. 1937 елда 4415 каралган эшнең 2163 дә үлемгә хөкем ителә. Алар арасында Казанның С. Вахитов, Я.Хисметдин кебек күренекле имамнар бар. Шул чакта 42 имам җәзага тартыла.

Үзен һәм гаиләсен нәрсә көткәнен белеп, С.Бикбулатов качмакчы була. Бу турыда аның хезмәт кенәгәсенең КДУда калуы дәлил. Хатыны Зөләйха мәктәптә укытучы булып эшләгән, кызлары Халидә һәм Фәридә Казан медицина институтында, улы Илгиз 7 нче сыйныфта укыган. Алар Казан шәһәре, Калинин урамы, 36 йорт, 3 нче фатирда яшәгән. Ләкин ниятен тормышка ашыра алмый. Басым ясауларга түзә алмыйча, 1954 елның 20 ноябрендә 68 яше туларга 7 көн калган дин эшлеклесе, югары уку йортларында куллланырлык дәреслекләр, уку әсбаплары калдырган зур шәхес С.Бикбулатов үлеп китә.

С.Бикбулатовның тормышына һәм эшчәнлегенә мөнәсәбәт төрлечә. Ләкин шуны истән чыгарырга ярамый: җәмгыятьтә кискен үзгәрешләр вакытында ул зур сынауларга дучар булган. Ни генә булмасын, ул олы хөрмәткә лаек шәхес.

**Марат хәзрәт МӘРДАНШИН,**
**Ютазы мөхтәсибе, төбәк казые, «Фәнис» мәдрәсәсе директоры**

**(Мәкаләнең тулы вариантын "Хозур" нәшриятында басылып чыгачак "Татар дин әһелләре" китабыннан укый аласыз)**

# 12 (245) декабрь 2015/ сафәр-рабигыльәүвәл –1437

# Могҗизалар иясенә салаватлар әйттек!

**Әйе, барлыкларның иң хәерлесе, караңгылык эчендә нур булучы сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмне котлап бөтенебез басып салаватлар әйттек; киләчәгебезнең асыллары – Булатның азан әйтүен, 4 яшьлек Тимерханның “Әлхәм”не укуын, Наил, Камилә, Энҗеләрнең остазбикәләре Фәния абыстай сорауларына тапкыр җавапларын тыңлап бик тә хозурландык вә күңелләребез тулы шатлык хисләреннән чиксез шөкерләребезне укыдык. Әйтерсең лә, дөньябыз иминлектән балкыды; яңгырда чыланып, карлы-сулы урамнарда бата-чума килүләр дә, Сүрия дә, Мисыр, Париж, Мали, Төркия дә "онытылды"...**



Гадел мәчетенә мин үзем һәрчак ашкынып киләм, бәйрәмнәрдән рухланып, җаннарым сафланып кайтам. Бу юлы да шулай булды. Биредә олылап уздырыла торган Мәүлидне һаман яңа эчтәлекләр, яңа гүзәл бизәкләр белән баеталар. Болын чәчкәләрен хәтерләткән берсеннән-берсе матур балаларыбызның Пәйгамбәребезнең кешелек дөньясына үрнәк гомер юлы турында хәбәрдарлыгын гына күр син! Мәчетнең уку-укыту эшләре җитәкчесе Фәния абыстай Җәләлиеваның һәм бүгенге көндә җитмештән артык балага, йөзләгән өлкәннәргә гыйлем бирүче мөгаллимәләрнең - озак еллар буе Коръән нигезләрен шушы балаларның әти-әниләренә, әби-бабайларына өйрәткән Рәсилә Сафина, Наҗия Азизова, Каимә Габделхәй кызы кебек 12 остазның олы җаваплылыгына, осталыгына, фидакарьлегенә дәлил түгелмени болар!

Килеп керүгә каршыдагы “Алмазыбызга ярдәм итик!” – дигән белдерүгә күзем төште. Өстәлдә киемнәр, кирәк-ярак әйберләр өелгән, шунда ук 3 литрлы банка тора. Килүчеләр арзан гына бәягә кием-салым ала, алмаучылар банкага акчасын сала. Кием сатудан кергән акча да шул савытта – ул инде тулып килә. Мәчеттә укып йөргән Алмаз каты авырый ди, менә аңа ярдәм оештырганнар, рәхмәт дими ни дисең! Раббыбыз Алмазыбызга терелеп, мәчеткә кайтырга, яшьтәшләре белән бергә ислам гыйлемнәрен үзләштерергә насыйп итсен!

- Дин гыйлеме – бәхет ачкычы, максатыбыз – балаларга ислам нигезләрен сеңдерү. Ә Мәүлид кичәсе үткәреп, дөньяның иң гадел кешесенең иман юлындагы аяусызлыгын, ныклыгын балалар күңеленә сеңдерергә телибез, - диде бәйрәмне ачканда Фәния абыстай. – Атна буе мәктәптә укып арыган балаларыбызның якшәмбе көнне татлы йокыларыннан торып, сәгать 9 га мәчеткә килеп җитүләре нинди сөенеч! Шөкер, тырышулабызыбыз юкка түгел.

Рөстәм хәзрәт Бакировның дә бәйрәм сәламнәрен, балаларга, олыларга изге теләкләрен тыңлап хозурландык:

Мәчетебезнең дәрәҗәсе еракларга барып җитте. Кукмара районының Өркеш авылында төзелгән “Фәниябикә” мәдрәсәсе турында хәзер кем генә белмидер, чисталык, матурлык чәчүче үзәк бит ул. Әнә бит Себердән кайтып урнашкан рус малае Витя да: “Монда миңа бик ошый. Малайлар белән бергәләп гарәп телен, ислам динен өйрәнәм”, – ди бит. Әйе, динебезнең асыл, гадел дин икәнлеген барысы да күрсен, белсен дип эшлибез.

Барыбыз да басып мәчет намазы укыдык. Һәм Фәния абыстаебыз өләшеп чыккан “Балаларга тәүфыйк сорап укыла торган дога” (Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдин) китапчыгыннан карап салаватлар әйттек. Кызлар, малайлар төркемнәре Фәния остазбикәләренең сорауларына җаваплар биреп, өйрәнгән аять-сүрәләрен укып күрсәтте. Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәдә укучы Кадрия Гадел мәчетендә бәләкәчләрне Нурания системасы буенча укытуны оештырган икән. Бу төркем дә үзенең сәләтен, белемен күрсәтте.

Бәйрәмне олылап килгән Татарстан Мөслимәләр берлеге рәисе Наилә Җиһаншина мәчетнең нәтиҗәле эшләре өчен рәхмәт һәм куану хисләрен җиткерде:

– Кадерлеләрем, - диде ул киң елмаеп, - сезгә мөфти хәзрәтләренең тәбрик сәламнәрен җиткерәм. Шушы мәчеткә килүегез белән сез инде бәхет юлына аяк басkансыз. Гомерегез буена шушы изге юлдан барыгыз, читкә тайпылмагыз. Халкыбызның горурлыгы булып үсүегезне телим!

Нагорный бистәсе мәчете остазбикәсе Рәшидә абыстай бу мәчеткә аеруча рәхмәтле икән.

- Даимә абыстай белән мәдрәсә төзергә хыялланып чыгып киттек шәһәр буйлап. Биредә безне шундый җылы каршы алдылар. Имам исе китеп: “Менә бит нинди әбиләребез бар, әлхәмдүлилләһ”, – дип куәтләп, кесәсеннән шундук меңү сумны чыгарып бирде, төзелеш мәшәкатьләренең тәртибен өйрәтте. Фердинанд хәзрәтебезнең рухлары шат булсын, догадан калдырмыйбыз.

Без дә сездән калышмыйбыз, мәчет, мәдрәсәбез бистәнең нуры, үзәге, шөкер. Өркештәге уңышларыгызны да өйрәнәбез. Андагы матур табигать, андагы халыкның игелеклелеге, каникулларда гы балаларның гаҗәеп гамәли яллары – чын иманлы яшәү үрнәге ул. Аллаһының рәхмәтләре яусын, әҗер-савапларын насыйп итсен!

Татарстанның атаклы абыстае исемен алган журналист Василә Рәхимова ике оныгын ияртеп килгән иде. Күп еллардан бирле бу мәчет белән дустанә мөнәсәбәттә булуына сөенүен, динебезне ныгытудагы биниһая күркәм эшгамәлләре өчен рәхмәт хисләрен җиткерде.

Балаларга бүләкләр өләшенде, тәмле ризыклар белән әзерләнгән чәй өстәле янында әле котлашулар дәвам итте. Яңа хаҗиләр дә бәхетле сәяхәтләре турында сөйләп, зәм-зәм суларыннан авыз иттерде. Бу иминлекләр бөтен дөньяда булса иде дип ялварып, биргән нигъмәтләре өчен Раббыбызга шөкераналар укыдык. Дөнья мөселманнары Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм юлыннан тайпылмасын иде, исламыбызга тап төшерүчеләр тиешле җәзаларын алсын иде, дигән бердәм теләктә калдык.

**Мөслимә ШӘФЫЙК**

# Пәйгамбәребезне олылау, зурлау ае

**Мөселман дөньясында өммәттәшләрем көтеп ала, аеруча активлаша, аралаша торган айлар, көннәр бар. Рамазанда, татарлар Корбан ае дип йөрткән зөлхиҗҗәдә һәм рабигыльәүвәл аенда бергәләп мәҗлесләргә җыелулар, ошбу айлар уңаеннан дәгъват дәресләре, бәйрәм мәҗлесләре уздырулар ешая.**



Шәһәр транспортында кая да булса барырга чыксам, берничә дин кардәшемнең җыелышып мәҗлескә ашыгуларына юлыгам. Юк, тирәяктагылар сокланып карарлык матур киенүләре, өс-башларының күркәмлеге генә түгел, үз-үзләрен тотышындагы әдәп-инсаф, итәгатьлелек “сата” мөслим-мөслимәләребезне. Бербереbезне ерактан ук танып, мөселманнарча сәламләшү исә күңелләребезне баета.

Быел да декабрь ае керүгә, өммәтебез Мәүлидне каршылау хәстәрен башлады. Башкалабыз мәчет-мәдрәсәләре гүя узыштан бу айда тагын да күбрәк изгелекләр кылып калырга, нәсыйхәтләнергә, Аллаһы Тәгаләгә якынаерга ашыгалар. Аларда ислам динебез асылын һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бу юлдагы тырышлыгын, безгә мирас итеп калдырган яшәү рәвешен бәйнә-бәйнә төшендерү ниятеннән мәҗлесләр гөрли. Пәйгамбәребез тормышы – безгә маяклы юл булуын галимнәребез, имамнар, абыстайлар аңлатып торалар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең эш-гамәлләрен, әхлагын сөйләп, аңарга күркәм төстә иярергә өндиләр.

Сафәр ае тәмамланган кичтә Кабан арты мәчете мәхәлләдәшләрен рабигыльәүвәл ае башлану белән котлап, күңелләрне баетырлык, ай буена күпкүп саваплар эшләрлек гамәлләргә чакырды. Ястү намазыннан соң җыйнак, җылы фарыз залы хәзрәтләрнең борынгы китаплардан, әби-бабаларыбыздан өйрәнеп калган, буыннан-буынга, телдән-телгә күчеп, безнең көннәргә килеп ирешкән Мәүлид салаватлары, касыйдәләр, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне олылаган мөнәҗәтләргә күмелде. Җәмәгать белән дә әйттек Мәүлид салаватларын. Халык авыз иҗаты җәүһәрләре булып саналган мөнәҗәтләрне яратып башкаручы, халкыбыз күңеленә ирештерүдә һәрдаим тырышлык куйган сәнгать әһелләре Миңгол Галиев һәм Рәшит Сөләймановны тыңладык. Күркәм мәҗлестә якшәмбе мәктәбендә динебез нигезләрен өйрәнүче ир балалар шулай ук салават әйтеп, Пәйгамбәребезне зурладылар.

- Кабан арты мәчетенең кабаттан ачылуына 25 ел тулды. Мәчетебез ел саен Мәүлидне билгеләүгә зур игътибар бирә. Без моның белән халыкны динебезгә якынайтырга, аның асылын күңелләренә Пәйгамбәребез мисалы аша төшендерергә омтылабыз. Максатыбыз кешеләрне белемгә һәм мәрхәмәткә чакыру.

(Ахыры 13 нче биттә.)

# Пәйгамбәребезне олылау, зурлау ае

**(Ахыры. Башы 12 нче биттә.)**

Моны Пәйгамбәребезнең туган көнен оештыру дип аңламагыз. Аның якты үрнәгән кабат-кабат искә төшерәбез. Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш рәвеше, кешелеклелеге бөтен дәверләргә, бөтен кыйтгаларга маяк булып тора. Ул исламның чын-чынлап тынычлык дине булуын раслый. Мәүлид кичәләренә җыелып, вәгазьләнеп, нәсыйхәтләр алып, без дә Казаныбызда мәрхәмәтлелек киң таралуын, инсаннарыбызның шушы белемнәр аша иманнары ныгуын телибез, - диде Сәетҗәгъфәр хәзрәт Лотфулла рабигыльәүвәл аена багышлаган мәҗлеснең ниятен ассызыклап.

Кабан арты мәчете ашханәсенә җыелган хатын-кызлар җәмәгате исә байтак еллар элек шушы мәдрәсәдә белем эстәгән, хәзер Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәдә мөгаллимлек итүче Фәния ханым Җәләлиеваны тыңлады. Ул Пәйгамбәребезнең җир йөзендә тоткан урынын, мөселманнар өчен никадәрле дә кадерле булуын сөйләде.

- Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм 23 ел буена Аллаһы Тәгалә гыйлемен төрле илләргә таратып, сәхабәләре белән бергәләп тормышка керткән, дәүләтләр төзеп, төрле диндәге халыклар белән тату, тыныч яшәү үрнәген калдырган. Пәйгамбәребезнең яшәү рәвеше сөннәт гамәл булып безнең көннәргә килеп җиткән. Шуңа шөкер итәбез, шатланып олылыйбыз. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне олылауны, ул дөньяга килгән рабигыльәүвәл аен зурлауны яшь буыннарга аңлата, аларның күңелләренә илтә алуыбызга да шөкер итәбез, - диде Фәния ханым.

Дин тыелган совет чорында Мәүлид йолалары онытылган иде дигән сүзләр ишетелгәли. Бик үк килешәсе килми. Узган гасырның 60-70 нче елларында Дәү әнидән: "Мәүлид җитә, аш уздырып аласы иде. Якын-тирәдәгеләрне мәүлид мәҗлесенә чакырырбыз", - дип алдан ук хәстәрләнүен хәтерлим. Һәм Пәйгамбәребезне олылап уздырылган мәүлид ашларын бигрәк тә хатын-кызлар үз итә иде дип беләм. Дин тотуга төрле кысулар, кисәтүләр булса да, безнең дәү әниләр, ак әбиләр әллә ни "баш бирмәгән": Корьән мәҗлесләрен үткәргән, әледән-әле җыелышып Аллаһка сыенган. Дин-исламыбызга тугрылыклары, мәхәббәтләре яңа туган сабыйларга исем кушуда да күренә. Шушы изге айда ир бала туса – Мәүлет дип, кыз балага Мәүлидә дип кушканнар. Рәҗәп аенда туучылар – Мәһирәҗәп, Рәҗәп, ә рамазанда аваз салучыларны Рамазан, Бибирауза, Мәһирауза дип атаганнар.

Рабигыльәүвәл дәвам итә. Татарстаныбызның бик күп шәһәрләрендә, авылларында мөселманнарыбыз Мәүлидне билгеләп үтәләр, күңелләре нечкәргән хәлдә, күп-күп салаватлар әйтеп, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шәфәгатен сорыйлар.

**Вәсилә РӘХИМОВА**

# Никах ул – изге гамәл

***"Кәбисә елны, ике гает арасында һәм сафәр аенда туй (никах) үткәрергә ярыймы?***

Динебездә мондый тыю юк. Бары гает җомга көнгә туры килсә, гает намазы укыгач, җомгага кадәр булган вакыт аралыгында гына никах уку киңәш ителми. Изге гамәлне никадәр иртәрәк кылсаң, шулкадәр хәерлерәк. Ә никах ул - изге гамәл.



Сүз уңаеннан, Пәйгамбәребез салләлаһу галәйһи вә сәлләм дә Гайшә анабыз белән ике гает арасында шәүвәл аенда никахлашкан.

Пәйгамбәребез салләлаһу галәйһи вә сәлләм: "Сафәр ае диеп шомланулар юк", - дигән. Икенче бер хәдисендә: "Диннең зәгыйфьләнгәнен шуннан белерсез, кешеләр төрле ырым-хорафатларга ышана башларлар һәм аны дин дип кабул итәрләр", - дигән.

Шомлануларга килгәндә, йогышлы авырулардан шикләнү (саклану) гына дөрес. Пәйгамбәребез салләлаһу галәйһи вә сәлләм: "Йогышлы авыру булган җиргә бармагыз, барсагыз аннан чыкмагыз", - дигән.

Егет белән кыз бер фикергә килеп, никах укытырга булганнар икән, беркем дә аларга сезнең аегыз, көнегез, елыгыз, сәгатегез туры килми диеп вәсвәсә салырга тиеш түгел. Бу эшне эшләгән кеше зур гөнаһлы була, моңа ышынган кеше көферлеккә чыга.

Шунысын да әйтергә кирәк, елның һәр көне ул ике гает арасы - Ураза гаете белән Корбан гаете яки Корбан гаете белән Ураза гаете арасы.

**Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ,**
**Татарстанның баш казые**

# Йокы әдәпләре

***"Соңгы вакытта начар төшләр еш күрәм. Иртән торгач, шомлы, авыр уйлардан кәефем кырылган була, аннары көне буе борчылып йөрим. Бу мәсьәлә буенча дин әһелләре берәр киңәш бирмәсләр микән? Эльвира".***

Йокы ул – Аллаһының кешегә ял итү өчен биргән бер зур нигъмәте. Кешенең йоклаган вакытта төрле төшләр күрүендә без белеп бетерә алмаган ниндидер мәгънә - хикмәт бар. Бер мөбарәк хәдисендә Мөхәммәд Пәйгамбәр салләлаһу галәйһи вә сәлләм төшләр турында әйтеп, мондый аңлатма бирә: "Төшләр өч төрле була: "Рахмәни" (Аллаһтан), "нәфсәни" (кешенең көн дәвамында уйлаган гадәти нәрсәләрне күрүе) һәм "шәйтани" (шайтаннан). Әгәр кемдер яхшы, күңеленә хуш килгән төш күрсә, дөреслектә, бу төш Аллаһтандыр. Мондый төшне күргән кеше Раббысына хәмед-сәнә (мактау сүзләре) әйтсен һәм күргәне турында кемгә тели - сөйләсен. Әгәр кеше начар, куркыныч төш күрсә, дөреслектә, бу төш шайтаннандыр. Бу очракта төшнең ямanлыгыннан Аллаһка сыенып, Аннан ярдәм сорарга һәм күргәнең турында беркемгә дә сөйләмәскә кирәк. Шулай эшләнсә, төшнең зарары кешегә тимәс". Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм начар төш күрүчеләргә шулай ук "Әгузү-бисмилләһ"не әйтеп, икенче якка борылып ятарга киңәш итә.



Начар төшне инде күргән кеше өчен әлеге хәдис бер киңәш-нәсыйхәт булып тора. Әмма начар төшләр күрмичә тыныч йокларга теләсәк, шәригатьтә каралган "йокы әдәпләре" дип атала торган кагыйдәләрне үтәү мәслихәт. Шушы әдәпләрнең беренчесе - иртәрәк йокларга яту (медицина галимнәре раславынча, организмны ял иттерә торган иң файдалы булган тирән йокы вакыты - ул төннең беренче өлеше (бигрәк тә төнге уникегә кадәрге вакыт аралыгы). Икенче мөһим әдәп - йоклар алдыннан күп ашамау. Тулы карынга йоклау нәтиҗәсендә организм тиешенчә ял итә алмый, шулай ук бу начар төшләр күрүгә дә сәбәп булырга мөмкин. Моннан тыш үзенең бер хәдисендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу хакта болай ди: "Тулы карынга йоклау күңелнең катылануына, кансызлануына китерә". Ә хәзрәти Гали ибне Әбү Талиб үз улы Хәсәнгә мондый киңәш биргән булган: "Әгәр шушы 4 нәрсәне онытмыйча тормышыңда кулланса, авырмассың һәм табибларга мохтаҗ булмассың:

- тамагың ачмыйча табын алдына утырма;
- ашарга утырсаң, өстәл янынннан тукланганчы торып кит;
- ашаганда ризыкны яхшылап чәйнә;
- йокларга ятар алдыннан бәдрәфкә кереп чыгарга тырыш.

Мөһим йокы әдәпләренең тагын берсе - йокларга ятар алдыннан тәһарәт алу (имам Җәгъфәр Садыйк билгеләп үткәнчә, тәһарәтле килеш йоклаган кеше өчен аның ятагы мәсҗид хөкемендә булыр, ягъни йокысы гыйбадәт булып саналыр). Төн җитеп йокларга җыенган кеше өй ишеген бикләп, ризык өстен капларга һәм утларны сүндерергә тиеш. Болардан тыш юрганны җиңелчә селкергә, урынҗирне сыпырып алырга да киңәш ителә.

Сөннәт буенча уң як янга ятып, уң кулны яңак астына куеп йоклау дөрес санала. Шулай ятканда йөзең кыйбла тарафына юнәлгән булырга тиеш (шушы рәвешле йоклау мөэминнәр йокысы дип атала). Баш очы белән кыйблага таба ятып йоклау да дөрес, әмма аякларны кыйблага таба сузып яту дөрес түгел. Шуңа да игътибар итәргә кирәктер: шәригать буенча йөзтүбән (эчкә) капланып йоклау ярамый (моның да начар төшләр күрүгә сәбәп булуы ихтимал). Йокы вакытында тәннең ябулы булуын, гаурәт җирләрнең ачылып китмәвен дә кайгыртырга кирәк.

Сөннәткә туры китереп яткач, "Аятел-көрси"не уку бик файдалы. Хәдисләрдә хәбәр ителгәнчә, йоклап китәр алдыннан "Аятел-көрси" укыган кешене фәрештәләр төне буе саклый, җен-шайтаннар исә бернинди зыян сала алмый.

Шунысы да мөһим: йокларга яткач, көн дәвамында башкарылган эшгамәлләреңне барлап, хата-кимчелекләрең, гөнаһларың өчен тәүбә итеп, Аллаһтан ярлыкауны сорарга, аннары исә синә ниндидер начарлык эшләгән, нинди дә булса зыян салган кешеләрне ихластан гафу итәргә кирәк. Бу чиста йөрәк вә тыныч күңел белән йоклап китәргә, төн дәвамында яхшы йокларга һәм ял итәргә ярдәм итәчәк.

Иртән торгач, битеңне кул учлары белән ышкып алырга һәм "Әлхәмдү лилләһ!" дип Аллаһны искә төшерергә кирәк. Торып утыргач, шушы доганы уку сөннәт булып санала: "Әлхәмдү лилләһилләзии әхйәәнәә бәгдә мәә әмәәтәнәә үә иләйһиннүшүүр" (улем биргәннән соң безне яңадан терелткән Аллаһка мактау булсын, без барыбыз да Аңа кайтачакбыз).

Менә шулай ислам әдәбе буенча йокласаң, иртән торып догасын укып, тәһарәтләр алып яңа көнне каршыласаң, шул көн дәвамында күңелең шат, күтәренке һәм тыныч булыр. Әлбәттә, моның нигез-максаты Аллаһ ризалыгын алу булырга тиеш.

**Ришат хәзрәт КУРАМШИН,**
**Кукмара мәдрәсәсе мөдире**

**Рәфыйк МӨХӘММӘТШИН:**

# "ДАИШ дип аталган сәяси проектның килеп чыгуы очраклы түгел"

**Узган айда гына дөньяда дистәгә якын теракт оештырылып, йөзләгән ватандашыбыз һәлак булды. Җинаятьләрнең күбесе ИГИЛ тарафыннан кылынган. Әлеге оешманың каян һәм ни сәбәпле барлыкка килүе, нинди максатка омтылуы турында Россия ислам институты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин белән әңгәмә кордык.**



### "Көнбатыш демократиясе мөселман илләрен болгатуга китерә"

**– Рәфыйк әфәнде, үгезне мөгезеннән тотыйк: нәрсә ул ИГИЛ?**

– Ливия, Сүрия, Ливан, Гыйрак территорияләрендә дәүләт булып берләшергә омтылучы экстремистик-террористик оешма. Күпчелек матбугат чаралары аны хәзер ДАИШ дип яза башлады, чөнки ИГИЛ, "ислам дәүләте" дип әйтеп, аны таныйбыз булып чыга, ә ДАИШ дип әйтү гарәп телендә тискәре мәгънәдә яңгырый. ДАИШ бик күп илләрдә (Россиядә дә) тыелган. Бүген ул Сүрия белән Гыйракның шактый территориясен яулап, күптән түгел Әфганстанга да омтылды.

Якын Көнчыгышта террористик оешмалар моңа чаклы да бар иде, әйтик, Әл-Каида. Ул төрле илләрдә шартлату, үтерү белән шөгыльләнә иде. Аңардан аермалы буларак, ДАИШ ислам дәүләтен төзү максатын беренче урынга куя, үзенә кирәкле чикләрне билгеләп, аларны киңәйтү белән шөгыльләнә. Гыйрак белән Сүриягә омтылулары очраклы түгел, чөнки анда нефть һәм газ бар. Төрле чыганакларга караганда, бу оешма аена, ким дигәндә, 50 миллион доллар акча эшли. Еллык кереме берничә миллиард доллардан арта, дип әйтәләр. ДАИШ нефтьне кая сата, дигән сорау бүген бик тә актуаль. Төркиядә хәрби очкычыбызны бәреп төшергәннән соң, Россия белгечләре ДАИШның нефтьне сату чыганакларын ачыклый башлагач, бу эш белән Төркиядәге кайбер дәүләт структураларының шөгыльләнгәне билгеле булды.

ДАИШ дип аталган сәяси проектның килеп чыгуы очраклы түгел. Очраклы килеп чыккан булса, ул шулкадәр зур территорияләрне яулый алмас иде. Таралып барган һәм нефтькә бай булган Ливияне карасак, аның җитәкчесе Муаммар Каддафиның Америка белән Европага мөнәсәбәте шактый тискәре булды. Гыйракны җитәкләгән Сәддам Хөсәен дә Америка белән тарткалашып торды. Нәтиҗәдә Каддафи да, Хөсәен дә үтерелде. Хәзер бу ике илдә гражданнар сугышы бара. Чиратта – Сүрия. Аның башлыгы Бәшәр Асадның Америка белән мөнәсәбәтләре шулай ук киеренке. Бүген Америка белән Европа, Асадны алыштырырга кирәк, дигән идеяне алга сөрә. Алар моны илдә демократия булмау белән аңлата. Ләкин проблема бит Якын Көнчыгыш илләренең диктаторлык режимы тарафдарлары булуында гына түгел, ә Көнбатыш сәясәтен алып бармауларында. Мөселман илләренең берсен дә демократик ил, дип әйтә алмыйбыз. Согуд Гарәбстанында да, Катарда да дәүләт белән корольләр, монархлар идарә итә. Алар алып барган сәясәт башка ил сәясәтләреннән әллә ни аерылмый. Тик шул ук вакытта Согуд Гарәбстаны, Катар, Кувәйт кебек илләр Америка белән тыгыз элемтәдә, үзләрендә аның сәясәтен алып баралар.

Сәясәтчеләр фикеренчә, туздырылган илләрдә хаос (тәртипсезлек) еш кына кемдер тарафыннан оештырыла. Америка да Якын Көнчыгышны территориаль һәм сәяси яктан үзгәртергә кирәклеге турында күптән сөйли.

Моңарчы ДАИШ Көнбатыш белән Америка өчен уңайлы проект иде. Алар алып барган сәясәтнең бер максаты – мөселман илләрен территориаль яктан үзгәртеп, яңа хөкүмәтләр оештырып, аларның башына үз кешеләрен кую иде. Әмма бүген алар да бу мәсьәләгә башкача карый башлады. ДАИШ, Якын Көнчыгыш территорияләреннән чыгып, Европага якынлашты. Сүриядән генә биш миллионга якын кеше чыгып качарга мәҗбүр булды. Күбесе Төркия аша Европага омтыла. Тагын кая барсыннар инде? Мөмкинлек булса да, икътисади яктан артта калган Африка, Мисырга баруның мәгънәсе юк, анда шул ук ачлык булачак. Германиядә ел ахырына кадәр мигрантларның саны бер миллионга кадәр артуы мөмкин, ягъни бу – Европа өчен дә планлаштырылмаган күренеш. Дөрес, Көнбатышка бүген арзан эшче көчләр кирәк. Европа үзе дә, халкы да шактый "карт", үзенең эшче көчләре бик кыйммәт, ике мең евродан да арзанга эшләүче юктыр, мөгаен. Килгән яңа яшь көчләрне арзанга эшләтергә, икътисади һәм демографик проблемаларны хәл итәргә мөмкин.

Европага миллионлаган кешенең читтән агылуы аның йөзен дә үзгәртә ала. Мөселманнарның саны бик тиз арта. Мәсәлән, Франциядә алар бөтен халыкның 10 процентын тәшкил итә инде. Әмма килгән кешеләр адаптация узмый, ягъни Европа сәясәтен кабул итмичә, ничек тели, шулай яши. Шуңа күрә Якын Көнчыгыштагы проблемалар бүген Европа проблемаларына әйләнә башлады.

Франциядәге шартлатулардан соң Бөекбритания дә ДАИШка каршы көрәштә актив катнаша башлады. Америка, әлеге террористик оешма белән көрәшергә кирәк, дип күптәннән әйтә килә, әмма реаль көрәш күрсәткәннәре булмады. Чөнки бүгенгә чаклы оешманың территорияләре дә киңәя, нефтьләре дә сатыла барды.

ДАИШның дәүләт буларак ныгуы бөтен дөнья җәмәгатьчелеге өчен бик куркыныч. Бер ике ел эчендә аның нинди афәтләр китерәчәгенә җитдирәк караган булсалар, ул барлыкка килмәгән дә булыр иде. ДАИШ үз инфраструктурасын булдыра – юллар, хастаханәләр төзелә, салымнар җыела, хәтта үзләренең министрлыклары бар. ДАИШ үзен террористик оешма гына түгел, чыннан да, дәүләт буларак хис итәргә омтыла.

**– Ә дини дәүләттә демократия булырга мөмкинме соң?**

– Демократия, төшенчә буларак, Европада формалашкан, шуңа күрә мөселман дәүләтләренә Европа демократиясен турыдан-туры күчереп булмый. Мөхәммәд Пәйгамбәр үлгәннән соң, дәүләтнең җитәкчеләрен сайлап куйганнар, димәк, исламда демократик принциплар бар. Ислам цивилизациясе Европа цивилизациясеннән тамырдан аерыла, исламны динигә һәм дөньявига бүлеп карау юк, шуңа да Европага хас булган демократик принциплар мөселман дәүләтләренә хас түгел. Гомумән, билгеле бер гомуми демократик кысалар нигездә үк юк. Америкада – либераль демократия, Европаны алсак, Франциядә демократия бер төрле, Бөекбритания – конституцион монархия, анда демократик принциплар гел башка. Тышкы көчләрнең, әйдә, мөселман илләрен демократик итеп эшлик, дигән сүзе тышкы сәяси мәнфәгатьләрен тормышка ашыру нияте генә. Мөселман илләренә демократияне көчләп тагу аларны болгатуга гына китерә.

Мөселман дөньясы белән Европа мөнәсәбәтләре XVIII гасырдан диярлек шактый катлаулы. Көнбатыштан берәр мөселман дәүләтенә демократик принциплар китерелеп, ул дәүләт яхшы яшәп килә, дип әйтерлек бер мисал да юк. Стратегик яктан мөһим булган төбәкләрдә һәрвакыт гражданнар сугышы бара. Әфганстанда байлыклар булмаса да, анда сугыш гасырлар буена барган, чөнки ул стратегик яктан мөһим. Гыйракны болгатып ташладылар, әмма анда берниндди демократия юк. Европа өчен мөселман илләре колония булган һәм бүген дә ул постколониаль синдром белән яши.

### "Мөселман дәүләтләрендә башка дин вәкилләре тыныч яшәгән"

**– Күпләрнең, аеруча башка дин вәкилләренең эчен пошырган сорау: ДАИШның Ислам диненә катнашы бармы?**

– Алар, шәригать кануннары буенча яшибез, шәригать кануннарына нигезләнгән чын мөселман дәүләте төзибез, ди. Бәлки, алар намаз укыйлардыр, Коръәнне чыганак буларак таныйлардыр, шуңа да беркем, алар мөселман түгел, дип әйтә алмый. Әмма үзеңне мөселман дип тану һәм шул ук вакытта кеше үтерү – икенче мәсьәлә. Кемдер кеше үтерсә, аны "син мөселман түгел" дип әйтеп, үз өстебезгә андый җаваплылык ала алмыйбыз. ДАИШ тарафдарларында ислам кануннарын дөрес аңлау юк, дип әйтергә мөмкин.

Ислам дине тарала башлаганнан бирле, мөселман дәүләтләрендә яһүдләр дә, христианнар да шактый тыныч яшәгән, аларга өстәмә салым гына түләргә кирәк булган. Европада яһүдләрне эзәрлекли башлагач, алар мөселман илләренә күчеп килгән. Башка дин әһелләрен, сез чын мөселман түгел, дип, мөселманнарны үтерү һәм шул рәвешле ислам кануннарын тормышка ашыру – исламга хас нәрсә түгел. Тарихка карасак, җиденче гасырда хариҗиләр булган, алар, син гөнаһ эшләдең, син кяфер, үзеңне исламлыктан чыгардың, дигән шигарь белән, кешеләрне үтерә торган булган. Әмма аларның чоры тиз – сигезенче гасырда тәмамлана. ДАИШны да хариҗиләрнең яңа чагылышы, дип әйтергә мөмкин. Аны ислам кануннарын дөрес тормышка ашыручы дәүләт дип атый алмыйбыз, ул аңа якын да тормый.

**– ДАИШ сафларына дөньяның төрле почмакларында яшәүче кешеләр килеп кушыла. Вербовкалаучылар, ягъни яллаучылар үз эшләрен яхшы башкара, дигән сүз. Алар моның өчен нинди ысуллар куллана икән?**

– ДАИШ кешеләрне яллау белән профессиональ рәвештә шөгыльләнә, моның төрле юллары бар. Җәмгыятьнең төбендәге кешеләргә кемнәдер үтерү, җәзалау турындагы видеороликларны күрсәтеп, үзләренә җәлеп итәләрдер. Тормышта утырып чыкканнар, тормышта үз урынын тапмаучылар ДАИШка үзләренчә гаделлек эзләп китәләрдер. Ярлырак төбәкләрдә, без нефть сатабыз, инфраструктурабыз, эш урыннары бар, дип, икътисади якка басым ясала. Хатынкызларны, бездә чын, гайрәтле ирләр бар, алар сезне матди яктан тәэмин итәчәк, дип ышандыралар.

**(Ахыры 15 нче биттә.)**

# “Азан” радиосы әниләргә багышлап бәйрәм уздырды

**“Азан” үзенең туган көнен әниләргә багышлап уздырды. Казанның Гаилә мәчетендә үткән әлеге бәйрәм-тамашага радиотыңлаучылар, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм “Хозур” нәшрият йорты хезмәткәрләре чакырылган иде.**

“Азан” мөселман интернет-радиосы кыска гына вакыт эчендә радиотыңлаучыларның чын дустына, киңәшчесенә әверелде, аларның ихтирамын казанды. Радионы даими тыңлап баручылар бу сүзләр белән, һичшиксез, килешер. Ә менә әлегә таныш булмаганнарны таныштырып үтәргә кирәктер.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан 2013 елны гамәлгә куелган “Азан” интернет-радиосы тәүлек буе рус, татар, гарәп һәм төрек телләрендә сөйләп тора. Радио коллективы киң җәмәгатьчелеккә исламның чын рухи кыйммәтләрен җиткерүне; динебезнең тынычлык, ышаныч, өмет кебек ихлас хисләргә нигезләнгән булуын төшендерүне; мөселманнарның дуслык, татулык, үзара хөрмәт кебек принципларга тугры булуын күрсәтүне максат итеп куя. Радио дулкыннарында дини, мәгълүмати, әдәби, социаль һәм мәдәни тапшырулар алып барыла. Көн саен эфирда Татарстан имамнарының вәгазьләре яңгырый. Иң кызыклы һәм актуаль темаларга сөйләшү өчен студиягә әйдәп баручы дин әһелләре, танылган җәмәгать эшлеклеләре, мәртәбәле белгечләр һәм экспертлар чакырыла. Туры эфирлар сишәмбе көнне Илмир Хәбибуллинның “Гамьле әңгәмә” дип аталган авторлык тапшыруы белән башланып китә. Һәр чәршәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә исә алып баручылар Ихсан Кышкар белән Айгөл Шәрипова студия кунаклары белән актуаль темаларга рус телендә – “Кстати говоря” тапшыруында әңгәмә кора.





Радиотыңлаучыларның Казанның Кол Шәриф мәчетеннән җомга вәгазьләрен турыдан-туры трансляциядә тыңлау мөмкинлеге дә бар. Радио дулкынында көнгә биш тапкыр азан әйтелә, төн уртасына кадәр Изге Коръән аятьләре яңгырый.

“Пәйгамбәребез медицинасы” тапшыруында сәламәтлекне саклау, төрле авырулар һәм аларны дәвалау турында Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең әйткәннәре тапшырыла. Ике телдә чыга торган “Фәтвалар” тапшыруын тыңлап ислам, әхлак, шәригать буенча кызыксындырган сорауларга җавап табарга була. Тапшыру өчен фәтва әзерләүче галимнәр арасында – мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин да бар.

“Азан” һәрдаим яңа тапшырулар тәкъдим итеп, тыңлаучыларын сөендереп тора. “Парчалар”, “Исламда – хатын-кыз”, “Сак булыгыз! Секталар!” дип аталган тапшырулар да үз тыңлаучыларын табып өлгерде инде.

“Азан” интернет-радиосын www.radioazan.ru сайтында тыңларга, ә сораулар һәм комментарийларны “Азан” радиосының ВКонтактедагы рәсми төркемендә (http://vk.com/radioazan) калдырырга була.

Инде Гаилә мәчетендә узган бәйрәмгә әйләнеп кайтыйк. Татарстан мөфтие урынбасары, Гаилә мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, “Азан”радиосын туган көне белән котлап, коллективка ихлас теләкләрен ирештерде һәм ислам кыйммәтләрен халыкка җиткерүдә алып барган хезмәтләре өчен рәхмәт әйтте.

“Хозур” нәшрият йорты директоры урынбасары Алмаз Әхмәтҗанов - радионы оештыруда башлап йөрүчеләрнең берсе. Ул үзенең котлау сүзендә болай диде: “Балалар – безнең киләчәгебез. Ә аларны аналар тәрбияли. Быел “Азан” радиосының туган көне нәкъ менә Әниләр көненә туры килде. Һәм без бик рәхәтләнеп бәйрәмебезне әниләргә багышларга булдык”.

Бәйрәм балаларның да, әниләрнең дә күңеленә хуш килде. Төрле әкият геройлары, чып-чын фокусчылар-тылсымчылар, татлы мамык, поп-корн ише тәм-том әзерләүчеләр бәйрәм дәвамында балаларның күңелен күрде. Ә өлкәннәр өчен “Азан”лылар ислам диненә, сөекле Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлына, татар дин галимнәре мирасына багышланган сораулардан викторина әзерләгән иде. Соңыннан “Азан” кунакларын 10 килолы бәйрәм торты белән сыйлады.

# "ДАИШ дип аталган сәяси проектның килеп чыгуы очраклы түгел"

**(Ахыры. Башы 14 нче биттә.)**

Динне белмәүчеләр арасында, ислам дәүләтен төзүдә мин дә катнашыйм әле, дип китүчеләр дә бардыр. Ләкин дини белеме булган кеше бу әйберләргә аек карый. ДАИШ сафларында БДБ илләреннән биш-алты мең чамасы кеше бардыр. Россиядә мөселманнарның 20 миллион икәнлеген исәпкә алсак, бу – кечкенә сан.

ДАИШка дөнья буйлап кешеләрне җәлеп итү өчен, тәрҗемәчеләр, мәгълүмати технология белгечләре кирәк. Күптән түгел кешеләрнең башларын чабулары күрсәтелгән өч-дүрт минутлык бик агрессив русча әзерләнгән видеоролик дөнья күрде. Нормаль психикалы кешегә моның белән уңай тәэсир итеп булмый, әлбәттә. Шул ук вакытта террорчылар халык арасында шом тудырырга омтыла.

## “Ислам телеканалының җәмгыять өчен файдасы зур булыр иде”

**– Татарстанда ДАИШ тарафдарлары бармы?**

– Вербовкалауны алып бару өчен Татарстанда утыру кирәкми, алар бу эшне интернет аша башкара. Бу мәсьәләдә ДАИШ мөселманнар яшәгән төбәкләргә аеруча зур игътибар бирә. Бүген республикада аның тарафдарлары күптер, дип уйламыйм, чөнки бездә беренчел дини белем алу мөмкинлеге бар. Мәчетләр каршындагы курсларда 30 меңләп кеше укый. Террорчылар, бергәләп хәлифәт төзик, ди. Әмма, мөселман бары тик хәлифәттә яшәргә тиеш, дигән таләп юк. Киресенчә, мөселман үз ихтыяҗларын канәгатьләндерә алырлык җирдә яшәргә мөмкин, диелә. Россиядә дини ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Татарстанда 1500 мәчет, тугыз дини уку йорты эшли. Коръәндә, үз идарәчеңә буйсын, дигән сүз бар, әмма ул мөселман гына булсын, дигән идея беренче планга чыгарылмый.

Россия Сүрия территориясендә ДАИШка каршы турыдан-туры фронт ачкач, интернетта халыкны куркыту максаты белән төшерелгән сюжетлар артты. Күптән түгел интернетта, йөзен каплап, үзен Әл-Татари дип таныштырган берәүнең сөйләгән видеороликлары барлыкка килде. Сөйләмендә мишәр акценты сизелә, шул ук вакытта русчасы да, гарәпчәсе дә камил. Ролик бик профессиональ эшләнгән. Сезнең дәүләтчелегегез булган, хәзер сез кяферләр кул астында яшисез, дип, татарларның милли аңына басым ясый ул.

Бүген яшьләр интернетта күп утыра, үзләрен борчыган сорауларга җавап эзли. Шуңа күрә без интернетта үз урыныбызны киңәйтергә тиеш.

Бездә укыган, әмма институтны тәмамлап бетерә алмаган бер яшь егет вербовкалау белән шөгыльләнеп, моның өчен берничә елга хөкем ителде. Безнең өчен бу, әлбәттә, борчулы күренеш. Дөньяви уку йортларында, башлыча, белем бирелсә, безнең өчен шәкертләрнең дөнья¬га карашын формалаштыру мәсьәләсе беренчел. Теге яки бу төбәктәге уку йорты студентлары террорчылар сафына кушыла икән, димәк, анда ниндидер проблемалар бар, дигән сүз. Безнең институтта ул яктан әлегә тыныч, бер ике очрак кына булып алды.

**– Иң якын дусларыбызның берсе – Төркиядән очкычыбызга арттан килеп һөҗүм итү кебек астыртын гамәл көткән идегезме?**

– Кайбер дәүләтләр сәяси мәнфәгатьләрен яклау өчен ДАИШтан файдаланып калырга тырыша. Америка төрекләрнең террорчылардан нефтьне арзанга алып, башка илләргә сатуын таныды бит инде. Төркия террористик җәмгыятьне хуплый, дип бик гадиләштереп әйтү дә дөрес булмас. Ул да шушы вазгыятьтән файдаланып калмакчы була. Төркиянең Сүрия белән мөнәсәбәтләре катлаулы, ул һәрчак Бәшәр Асадка каршы чыкты. ДАИШның Сүрия территорияләренең бер өлешен яулап алып, аны көчсезләндерүе Төркиягә, әлбәттә, файдага.

**– Күптән түгел Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ислам кыйммәтләре турында мәгълүмат бирерлек федераль телеканал ачу кирәклеге турында әйтте. Сез моңа ничек карыйсыз?**

– Бу мәсьәлә күптәннән күтәрелеп килә инде. Әл РТВ интернет канал буларак эшли башлады, әмма үсеп китә алмады. Бүгенге вакыйгалар күзлегеннән караганда, хөкүмәт өчен ул канал бик мөһим. ДАИШның асылына төшенү өчен әллә ни тирән белем дә кирәкми. Ул телеканал аша агарту эше алып барылыр, иң мөһим сорауларга җавап бирелер иде. Православ диненең “Спас” һәм башка каналлары бар. Мөселманнарга федераль каналларда мөнәсәбәт уңай булса да, чыгыш ясау өчен вакыт күп бирелми. Ислам динен яктыртя торган федераль канал барлыкка килсә, аның мөселманнарга гына түгел, бөтен җәмгыять өчен дә файдасы зур булыр иде.

***Линар ЗАКИРОВ,***
***“Шәһри Казан”***

# КАЗАН ӨЧЕН ГЫЙНВАР АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| КӨН | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ясту намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Таң беленә | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.01.2016 | 05:53 | 06:43 | 08:13 | 12:00 | 13:33 | 15:20 | 17:18 |
| 02.01.2016 | 05:53 | 06:42 | 08:12 | 12:00 | 13:34 | 15:21 | 17:19 |
| 03.01.2016 | 05:53 | 06:42 | 08:12 | 12:00 | 13:35 | 15:22 | 17:20 |
| 04.01.2016 | 05:53 | 06:42 | 08:12 | 12:00 | 13:36 | 15:24 | 17:21 |
| 05.01.2016 | 05:52 | 06:41 | 08:11 | 12:00 | 13:38 | 15:25 | 17:22 |
| 06.01.2016 | 05:52 | 06:41 | 08:11 | 12:00 | 13:39 | 15:27 | 17:23 |
| 07.01.2016 | 05:52 | 06:40 | 08:10 | 12:00 | 13:40 | 15:28 | 17:24 |
| 08.01.2016 | 05:52 | 06:40 | 08:10 | 12:00 | 13:42 | 15:30 | 17:25 |
| 09.01.2016 | 05:51 | 06:39 | 08:09 | 12:00 | 13:43 | 15:31 | 17:27 |
| 10.01.2016 | 05:51 | 06:38 | 08:08 | 12:00 | 13:45 | 15:33 | 17:28 |
| 11.01.2016 | 05:50 | 06:37 | 08:07 | 12:00 | 13:46 | 15:34 | 17:29 |
| 12.01.2016 | 05:50 | 06:37 | 08:07 | 12:00 | 13:48 | 15:36 | 17:31 |
| 13.01.2016 | 05:49 | 06:36 | 08:06 | 12:00 | 13:49 | 15:38 | 17:32 |
| 14.01.2016 | 05:49 | 06:35 | 08:05 | 12:00 | 13:51 | 15:40 | 17:34 |
| 15.01.2016 | 05:48 | 06:34 | 08:04 | 12:00 | 13:52 | 15:41 | 17:35 |
| 16.01.2016 | 05:47 | 06:32 | 08:02 | 12:00 | 13:54 | 15:43 | 17:36 |
| 17.01.2016 | 05:47 | 06:31 | 08:01 | 12:00 | 13:56 | 15:45 | 17:38 |
| 18.01.2016 | 05:46 | 06:30 | 08:00 | 12:00 | 13:58 | 15:47 | 17:39 |
| 19.01.2016 | 05:45 | 06:29 | 07:59 | 12:00 | 13:59 | 15:49 | 17:41 |
| 20.01.2016 | 05:44 | 06:27 | 07:57 | 12:00 | 14:01 | 15:51 | 17:43 |
| 21.01.2016 | 05:43 | 06:26 | 07:56 | 12:00 | 14:03 | 15:53 | 17:44 |
| 22.01.2016 | 05:42 | 06:25 | 07:55 | 12:00 | 14:05 | 15:55 | 17:46 |
| 23.01.2016 | 05:41 | 06:23 | 07:53 | 12:00 | 14:07 | 15:57 | 17:47 |
| 24.01.2016 | 05:40 | 06:22 | 07:52 | 12:00 | 14:09 | 15:59 | 17:49 |
| 25.01.2016 | 05:39 | 06:20 | 07:50 | 12:00 | 14:10 | 16:01 | 17:51 |
| 26.01.2016 | 05:37 | 06:19 | 07:49 | 12:00 | 14:12 | 16:03 | 17:52 |
| 27.01.2016 | 05:36 | 06:17 | 07:47 | 12:00 | 14:14 | 16:05 | 17:54 |
| 28.01.2016 | 05:35 | 06:15 | 07:45 | 12:00 | 14:16 | 16:07 | 17:56 |
| 29.01.2016 | 05:34 | 06:13 | 07:43 | 12:00 | 14:18 | 16:09 | 17:58 |
| 30.01.2016 | 05:32 | 06:12 | 07:42 | 12:00 | 14:20 | 16:11 | 17:59 |
| 31.01.2016 | 05:31 | 06:10 | 07:40 | 12:00 | 14:22 | 16:13 | 18:01 |

## “Хозур” яңа китаплар тәкъдим итә




“Хузур” нәшрият йорты ислам динен хәнәфи мәзһәбе буенча тотучы мөселманнар өчен бик борынгы заманнардан бирле иң мөһимнәрдән һәм кирәклеләрдән саналган китапларның берсе – Әбе-л-Хөсәен Әхмәд бине Бәкер Мөхәммәд бине Әхмәд Әл-Кодуриның **“Мохтасар әл-Кодури”** дип аталган хtзмәтенә һиндстанлы дин галиме Мөхәммәд Гашыйк Илаһи әл-Барның шәрехен, ягъни аңлатмасын нәшер итте. Әлеге китап **“Әт-Тәсһил әд-дарури ли мәсәил Әл-Кодури”** (“әл-Кодури мәсьәләләрен тиешлечә җиңеләйтү” дигән исем астында басылды.

***


Гөлфия Хәбибуллинаның **“Ислам фәннәрен укыту методлары”** дигән китабы уку-укыту эшләрендә мөгаллимнәргә теоретик һәм гамәли яктан, дини фәннәрне укытуда проблемалы мәсьәләләрне ачыклауда, методларны билгеләүдә ярдәм итүче уку әсбабы буларак тәкъдим ителә. Өч бүлектән торган китапта мөстәкыйль өйрәнү өчен шактый бай әдәбият исемлеге бирелә.




***

Р.Әдһәмовның **“Дингә өндәү нигезләре һәм имам вазыйфалары”** китабы дөнья күрде. Әлеге уку-укыту әсбабында Татарстан Республикасында дингә өндәү үзенчәлекләре турында мәгълүмат бирелә, имамның һәм вәгазьченең һөнәри вазыйфалары җентекләп аңлатыла. Биредә мөселман руханиларының вәгазь сөйләве, мәхәлләнең дини-мәгърифәти, юридик-икътисадый эшчәнлеге, җәмгыяви хезмәт, җирле мөселман дини оешмасы менеджменты кебек юнәлешләр өйрәнелә. Китап “Нур” нәшрият йортында басылган.







## “Азан” радиосы Мәүлид ае уңаеннан иҗади бәйге игълан итте

Мәүлид ае уңаеннан **“Азан” радиосы Пәйгамбәребез Мөхәммәд** салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә багышланган бәйге игълан итте. Анда теләге булган һәр кеше катнаша ала. Бәйгегә шигырьләр, хикәяләр, аудиоязмалар һәм башка жанрларда иҗат ителгән эшләр кабул ителә. Иҗади материалларыгызны radioazan@mail.ru электрон почтасына “бәйге” тамгасы белән җибәрегез. Алар “Азан” радиосы сайтында, социаль челтәрләрдә урнаштырылачак. Җиңүчеләрне шулай ук радиотыңлаучылар билгели. Югары бәя алган эш авторлары истәлекле бүләкләр, аудиодисклар һәм “Хозур” нәшрият йорты китаплары белән бүләкләнәчәк.



ДИН вә Мәгыйшәт
Ий мөэминнәр! Барчалагызыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез! (Коръән, 3:103)
Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга куллanудан сакланыгыз!
6+
Декабрь саны, №12 (245)

**Баш мөхәррир:** СӘМИГУЛЛИН К.И.
**Мөхәррир:** КӘБИРОВА Н.Н.
**Дизайнер:** МИҢНУЛЛИНА Г.Н.

**РЕДАКЦИЯНЕҢ ҺӘМ НӘШЕР ИТҮЧЕНЕҢ АДРЕСЫ:**
420021, Казан шәһәре, Сафьян урамы, 8 нче йорт
**Электрон адрес:** naubahar67@list.ru
**Телефон:** +7 950 326 38 36

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хузур» нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН;**
ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе **Нияз САБИРОВ;**
Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы әгъзасы **Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ: 16046**
**Татарстанның һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27).
**Нәшир:** «Хузур» нәшрият йорты (420021, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Сафьян урамы, 8 нче йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета **"Татмедиа" АҖ филиалы - "Идел-Пресс"** полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2).
**Тираж: 5 мең данә** Заказ **№ 9062**
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - **6 сум.**
График буенча бу санга **21 нче декабрь** көнне **21.00 сәгатьтә** кул куелырга тиеш иде.
Кул куелды: **21.00 сәгатьтә.**